Фардеева Васима





Галиуллина Алия




Финалистки самарского регионального отборочного этапа будут представлять Самарскую область в Москве. 7 декабря 2014 года в столице пройдет первый всероссийский фестиваль красоты «Татар кызы-2014» («Татарская красавица-2014»). Этот фестиваль призван перевернуть представление о классических конкурсах красоты – никаких дефиле в бикини, только женская красота, основанная на богатом внутреннем мире участниц и знании традиций своего народа. Конкурс проводится под руководством председателя Совета Федеральной национально-культурной автономии татар, депутата Государственной Думы РФ И.И. Гильмутдинова и при поддержке Министерства Культуры Республики Татарстан, Комитета Государственной Думы РФ по делам национальностей, Комитета Совета Федерации РФ по науке, образованию и культуре.

Через год – очередное испытание красоты, но первый конкурс навсегда останется самым запоминающимся. Он останется в памяти красивыми лицами, нарядными национальными костюмами, татарскими песнями, блюдами, полным залом гостей и прекрасной организацией!

Самое главное, что татарская общественность, в первую очередь в лице президента «Туган тел» Ильяса Гумеровича Шакурова, смогла организовать такой фестиваль красоты и привлечь внимание областных, городских властей, татарского населения, бизнесменов к возрождению национальной самобытности одного из крупнейших российских этносов. Мы в очередной раз убедились, что самарские девушки – самые красивые. Это видно даже из космоса! Теперь предстоит это доказать в Москве.

**Организаторы и спонсоры:**

**Информационные спонсоры:**



# “МОҢ ЧИШМӘСЕ”НЕҢ 35 ЕЛЛЫК ҖЫРЛЫ-КӨЙЛЕ ЯЗМЫШЫ

**Айсылу апа ӘБДИЕВАны юкка гына Самар өлкәсендәге “Ялкынлы яшьлек” җыр, бию һәм поэзия ансамбленең “моң чишмәсе” дип атап йөртмиләрдер. Ул милли көй-аһәңнәребезнең асылын аңлаган, татар җырларының бормаларын саклаган, моң агышын хәтерләткән чылтырап аккан чишмә суы сыман. Алай гына да түгел, Айсылу ханым - ансамбльдә ничәмә еллар эчендә алмашынган күп буын артистларын күргән “ветераннар”ның берсе.  Өлкәбезнең татар сәнгатендә алны-ялны белмәгән талантлы шәхесләрнең иҗади күтәрелешләрен, аянычлы язмышларын саклаган серле, асылташлар белән бизәлгән кыйммәтле һәм зәвыклы сандыкка тиң.**

**Римма НУРЕТДИНОВА**

Нәкъ 35 ел элек - 1979 елның октябрендә – яшь сылу кыз гади кызыксынудан «Ялкынлы яшьлек» ансамбленә килә. Җыр-моңга сәләтен тикшергән вакытта, халык көйләрен бик яратканга күрә, ул Таһир Якупов башкаруындагы “Карачтау авыл көе”н җырлап күрсәтә. Ә инде 2-3 атнадан соң кызны концерт программасына кертеп, сәхнәгә дә чыгаралар...

“Элек концертлар аншлаг белән үтә, тамашаларга күп халык йөри иде бит. Мин сәхнәгә беренче тапкыр аяк баскан көнне дә зал шыгрым тулы булды, ә үзем дер калтырап тордым. «Болыннарда йөрим сине уйлап» һәм «Әниемнең туган көне» җырларын башкардым да, кемне дә күрмичә, алкышларны да ишетмичә, сәхнә артына юнәлдем. Ә мине аннан кире сәхнәгә «бис”ка борып чыгардылар... Ул вакыттагы кичерешләремне беркайчан да онытмаячакмын, алар мәңгегә минем хәтеремдә уелып калачаклар”, - дип искә ала Самарның моңлы сандугачы.

**ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...**

Оясында ни күрсә, очканда шул булыр, диләрме әле? Чыннан да, Айсылу апага кечкенәдән милли көйләребезне тыңлап үсәргә туры килә. Куйбышев шәһәре читендә урнашкан өйләрендә тальян гармун моңнары бер дә тынмый һәм татар җырлары гаиләдә үскән кыз балаларга - Айсылу һәм Лилиягә - милли хис сала, туган телгә юл ача, сәнгатькә мәхәббәт уята.

Җыр-моңга әвәслек, мәхәббәт, гадәттә, нәселдән килә. Айсылу ханымның сәләте әнисе Зөләйха һәм әтисе Рәфыйк ягыннан да кучкән булса кирәк. Ульян ягыннан Куйбышевка килеп урнашкан яшьләр кайчандыр “пятачок” дип аталган, татарлар җыелып, күнел ача торган, төрле күмәк уеннар, җыр-биюләрдән гөрләп торган мәйданчыкта танышалар.

Айсылу апаның әнисе Зөләйха Иске Кулатка районының Бахтеевка авылында туып-үскән. Зөләйханың әнисе Сабира шулай ук искиткеч матур тавышка ия булган. Аның тамырлары Башкортостанның Илеш районына җәелгән. Үзе дә Илеш районында туган шагыйрь Роберт Миңнуллин бер әңгәмәсендә *«Моң Башкортостан татарларының каннарына сеңгән»*, дип бик дөрес сүзләр әйткән икән шул.

Сабираның гаиләсендә дин әһелләре булганлыктан, репрессия вакытында аларны гаепсезгә корбан итеп, Илеш районы Югары Манчар авылыннан ерак Себергә озатканнар.



*Кечкенә Айсылу әти-әнисе белән*

Шуннан бирле Айсылу апаның әбисе авылдашларына бик үпкәләп, хәтта гарьләнеп, үзенең туган туфрагына аяк басмаган, ә кече Ватанын сагынган саен, күзләреннән аккан яшьләрне тоя алмыйча, җырлаган.

Айсылу ханымның мәрхүм әтисе – Самар шәһәрендә яшәүче милләттәшләребезгә яхшы таныш булган Рәфыйк Әбдиев оста итеп гармунда уйнаган, "Ялкынлы яшьлек" ансамбле концертларында катнашкан, татар чараларында махсус бию мәйданчыклары булдырып, халыкның күңелен күргән. Гади эшче - йөк машиналарын йөртүче Рәфыйк әфәнде гармунын тартып җибәрсә, егетләрнең аяклары тыпырдый башлаган, кызлар күбәләктәй бөтерелеп биеп киткән. Оста гармунчының токымында талантлы скрипкачы да, тальянчы да, моңлы тавышлы җырчылар да булган.



*Рәфыйк Әбдиев милли көрәш үткәрелгән урыннарда да хәкимлек итә*



*Айсылу ханымның талантлы әтисе*

Ульян өлкәсенең Мәләкәс тирәсендә үскән Рәфыйк әфәндenең язмышы да җиңелдән булмаган. Аларның гаиләсе акча эшләр өчен Сахалинга кадәр барып йөргән, маңгай тирләре белән тапкан күп кенә мал-мөлкәтләрен туплап кайткан бер дәвердә Әбдиевларның өенә бандитлар килеп кергән һәм бөтен гаилә әгъзаларын суеп үтергәннәр. Ул вакытта әле кечкенә булган Рәфыйк кына исән кала. Ул мич артындагы капчыклар арасына качкач, бандитлар малайны пычак кадый-кадый эзләргә керешәләр һәм шул чакта аның сыртын нык җәрәхәтлиләр. Шул вакыттан калган җөй аңа гомер буе бу куркыныч хәл турында исенә төшереп тора. Тик бернинди кайгы-хәсрәт тә егетне музыкаsuccessны онытырга мәҗбүр итә алмый, һәм ул һәрвакыт елмаючан, көләч йөзле, аралашучан булып кала. Рәфыйк Әбдиев үз вакытында Ульян һәм Самар өлкәләрендә беренче гармунчы булып санала.

Айсылу апаның әтисе гармун һәм тальяннар коллекциясе дә туплаган, алар арасында өлкәбезнең атаклы гармун ясау остасы Гали Әбүбәкер улы Гәрәев тальяны да булган. 2003 елда, Рәфыйк әфәнде ватаф булып, аның музыкаль инструментлары тынып калгач, Айсылу апа аларны талантлы һәм моңа мохтаҗ булган милләттәшләренә тарата. Бүгенге көндә Әбдиевлар гаиләсендә бабаларының бары тик ике гармуны гына саклана: аларның берсе Самарда кызында булса, икенчесен оныгы Гүзәл үзе белән Берлинга алып китә.

Айсылу апаның әтисе гармунда уйнап кына калмый, өлкә "Туган тел" татар оешмасының әгъзасы буларак, милли көрәш үткәрелгән урыннарда да хәкимлек итә, татар чараларын уздыруда да бик актив катнаша.

## ҖЫРГА-МОҢГА ҮРЕЛЕП БАРГАН ТОРМЫШ ЮЛЛАРЫ

Бөтен гомерен җырга багышлаган, сәхнәдән тамашачыларга бары тик илаһи моң, елмаю бүләк иткән "моң чишмәсе"нең язмышы үзе кебек ягымлы һәм көләч йөзле булмый шул, ул язмам героен бик каты сыный. Яратып, матур киләчәк турында хыялланып, кияүгә чыкса да, тормыш иптәшеннән уңмый ул. Ире белән аерылгач, яңадан гаилә кормыйча, бар назын бердәнбер кызына - Гүзәлгә - бирә.

Тормышның ачысын күп татырга туры килә Айсылу ханымга, авыр үзгәртеп кору елларында үзен һәм баласын туендыру өчен армый-талмый көч түгә ул. Аның хезмәт юлы сатуда да, тегүчелектә дә, пешекчелектә дә үтә. Батыр, җитез хатын риэлтор булып та эшләп ала һәм кызы белән үзенә фатирлар булдыра. Шул ук вакытта читтән торып урта юридик белем ала. Аннан Самарның Совет районы администрациясенең социаль яклау идарәсендә игътибарлы, эшчеләрен хөрмәт итүче милләттәшебез Әлфия Нурислам кызы Мифтахова җитәкчелегендә юрист вазифасын башкара һәм идарә каршындагы "Дуслык" оешмасында культура-масса эшен дә алып бара. Совет районы пенсионерлары өчен төрле-төрле бәйгеләр, атаклы язучылар, шагыйрьләр иҗатына багышланган кичәләр оештыра.

Әлбәттә, җырдан-моңнан да аерылмый Айсылу Әбдиева. Үз халкын өзелеп яратучы милләтпәрвәр 35 ел дәвамында ансамбльнең концертларында һәм өлкәбезнең төрле милли чараларында даими чыгышлар ясый, концерт сценарийларын язуда да катнашып килә, яшь артистларга һәрьяклап



ярдәм итеп яши. Казан, Яр Чаллы, Нурлат, Түбән Новгород, Ырынбур, Яңа Куйбыш һәм башка бик күп шәһәрләр буйлап гастрольләрдә йөри, иҗади фестивальләрдә катнашып, призлы урыннарга лаек була. Мәсәлән, Самарда уздырылган V Бөтенроссия "Түгәрәк уен" фестивалендә дипломант исеменә ия була.

Соңгы елларда Айсылу Әбдиева Самарның Управленческий бистәсендәге «Чайка» Мәдәният йортында художество җитәкчесе, аннан мөдир урынбасары вазифаларын да башкара. Биредә фестивальләр, үзешчән сәнгать смотрлары, календарьдагы түгәрәк һәм истәлекле даталарга туры китереп, төрле чаралар оештыруда мөдир Гүзәлия Мөнип кызы Сафина белән бергә кулга-кул тотынып эшли. Әлеге гүзәл ханымнар нәрсәгә генә алынсалар да, башкаларга үрнәк булсын дип, бөтен энергияләрен биреп, алны-ялны белмичә, иңне-иңгә куеп тырышалар.

- *Ислам дине каннуннары буенча яшәүче һәм өч баласын да шундый рухта тәрбияләп үстерүче Гүзәлия Мөнип кызы — яңача фикер йөртүче җитәкче. Аның инициативасы белән искереп беткән "Чайка" Мәдәният сарае яңа сулыш алды: заманча ремонт ясалды, кирәкле техника кайтарылды, аудиторияләр матур итеп җиһазландырылды. Җылы һәм күркәм Мәдәният сараенда хәзер "Ялкынлы яшьлек" ансамбле репетицияләре һәм концертлары, "Туган тел" җәмгыяте, өлкә һәм шәһәр татар милли-мәдәни мохтариятләре, "Дуслык" оешмасы белән хезмәттәшлек итү нәтиҗәсе буларак, төрле милли чаралар уздырыла, - дип сөйли Айсылу ханым.*

Искиткеч җор телле, һәр эшкә бөтен җаны-тәне, барлыгы белән алына торган күркәм зат - Айсылу апа - биредә дә әйдәп йөрүчеләрдән була. Булдыклылыгы, эшчәнлеге белән ул мәдәният тармагында эшләүчеләрнең күңелен яулый.

Айсылу ханым "Чайка" Мәдәният йортында эшләгән дәвердә биредә нигезләнгән "Ялкынлы яшьлек» ансамблен аеруча кайгыртып килә, билгеле. Музыкаль инструментлар булдырырга, костюмнар тектерергә грантлар оту өчен документлар теркәүдә дә актив катнаша ул. Бергәләп, булсынга дип йөргән эшләренең нәтиҗәсе дә күңелле була.

Әйтеп үткәнемчә, 2003 елда язмам героеның искиткеч талантлы әтисе Рәфыйк әфәнде бакыйлыкка күчә һәм, кызганычка, бу югалтуны авыр кичергән хәләл җефете Зөләйха апа бик каты авырып китә. Үткән елда аның чире тагын да кискенләшү сәбәпле, кызы Айсылу эштән китәргә һәм читтән торып укый башлаган ике университетын да ташларга мәҗбүр була. Әмма хәзерге вакытта да Айсылу ханым "Чайка" Мәдәният йортының штаттан тыш хезмәткәрләре булып кала. Биредә чаралар үткәргәндә, концерт-тамашалар оештырганда, коллегалары, электән килгән дуслыкка нигезләнеп, әле дә аның белән киңәшеп эш итә, аның акыллы фикерләренә колак сала.

Шөкер, Айсылу ханымның тырышлыгы эзсез калмаган. Матур эшләрен күреп һәм бәяләп, төрле дәрәҗәдәге идарә башлыклары аны рәхмәт хатлары, грамоталар һәм дипломнар белән бүләкләгәннәр.



*Зөләйха һәм Рәфыйк Әбдиевлар кызлары, кияве һәм оныклары белән*



*Айсылу Әбдиева һәм Самарның «Чайка» Мәдәният йорты мөдире Гүзәлия Мөнип кызы Сафина кулга-кул тотынып эшләгән дәвердә*

"Ялкынлы яшьлек" ансамблендә күп еллар буена җырлавы нәтиҗәсендә профессионализм да, тәҗрибә дә туплаган Айсылу Әбдиева менә инде 15 еллар дәвамында Самарда тамада эшен дә бик уңышлы гына башкарып килә. Әлеге идея аңарда күптән барлыкка килгән булган. Иң элек аның инициативасы һәм "Туган тел" татар җәмгыяте вәкилләре Шамил Баһаутдин, Илгиз Колючев, Азат Нәдыйров ярдәмендә Самар шәһәре Промышленность районының Никахлар теркәү йортында милли киемнәрдән, татар халык гореф-гадәте буенча никах теркәү церемониясен күрсәтә башлаганнар. Хәтта бу тамашаны "ТЕРРА-НТВ" телеканалы да төшереп алган булган һәм әлеге гореф-гадәтне кайтарган өчен "Туган тел" оешмасына диплом да тапшырган. Кызганычка, төрле сәбәпләр аркасында бу эш тукталган, әмма әлеге сценарийны әзерләгән Айсылу ханым татар туйларында аны тормышка ашырырга булган.

Айсылу апа тамада эшен бик яратып башкара, чөнки аңа кешеләрнең куаныч-шатлыкларын күрү икеләтә сөенеч китерә. Әлеге туйларда ул үзенең аһәңле тавышы белән яшьләргә мөрәҗәгать итеп, йөрәккә үтеп керә торган матур сүзләрен җиткерә, туган телендә җырлар башкара, урыслашып барган милләттәшләребезгә татар телен белү буенча мастер-класслар да уздыра.

Шулай ук бу эштә аңа төрле елларда Илнур Алтынбаев, Гүзәл Фәхретдинова, Рияз Алтынбаев, Тәлгать Хәйруллов, Гөлфия Гайнетдинова, Искәндәр Әхмәтов, Гүзәл Курмаева кебек талантлы хезмәттәшләре дә ярдәм итеп килә, бүгенге көндә тамада бу эшкә яшь үзешчән артистларны да тартырга тырыша.




*Берлинда Гүзәл Курмаева фотосурәте төшерелгән «Контакт» журналы басылып чыга*

### «ЯЛКЫНЛЫ ЯШЬЛЕК» АНСАМБЛЕ БАЛАСЫ

Айсылу апаның үзе кебек ук талантлы кызы Гүзәл Курмаева да - «Ялкынлы яшьлек» ансамбле коллективында тирән эз калдырган шәхес.

Бабасының гармун моңнары һәм әнисенең матур тавышы тәэсире астында үскән кыз кечкенәдән матур итеп җырлый. Аның балачак хатирәләре - Мәдәният йортында репетицияләр, тере тавыш, бию, һәрвакыт яңа эзләнүләр.

Кызны алты яшендә музыка мәктәбенә укырга бирәләр. Аның беренче музыка укытучысы - Самар татарлары арасында иң хөрмәтле һәм танылган мөгаллим Рәмзия Шаркаева-Әмирова. Аның ярдәме белән кыз алты яшендә беренче музыкаль балалар иҗаты фестивалендә «Туган тел» җырын башкара.

*- Рәмзия ханым кебек җаны-тәне белән хезмәтенә бирелүче укытучылар бик аз, ул үзен җәлләмичә яшәде һәм эшләде, - дип сөйли Айсылу ханым.*

Озак вакыт кызның үзенең музыкаль инструменты булмый тора. Шуңа күрә ул өендә бармаклары белән өстәлдә уйнап, дәрескә әзерләнә. Ниһаять, соңрак бабасы аңа бер мең сумга ул вакытта бик кыйммәтле саналган «Элегия» пианиносын сатып ала, аннан немец аккордеонын да бүләк итә.

Бабасы һәм әнисе кызның музыка





Әни белән кыз - бер сәхнәдә

белән шөгыльләнүен бик телиләр, үзләренең тормышка ашмаган хыялларын нәкъ Гүзәлгә юнәлтәләр. Һәм кыз аларның өметләрен аклый: төрле концертларда катнаша, профессиональ дәрәҗәдә сопрано, альт партияләрен башкара.

Нәкъ «Ялкынлы яшьлек» ансамбле Гүзәлгә олы юлга аяк басарга ярдәм итә дә инде. Унбиш яшеннән бэк-вокал башкарып, чирканчык алган кыз бер-ике елдан соң үзе дә җырлый башлый һәм аңа беренче кыю чыгышы бик зур уңыш китерә.

Ансамбльдә нәселнең дәвам ителүен күрсәтеп, сәхнәгә өчәү бергә – бабасы Рәфыйк, энисе Айсылу һәм оныгы Гүзәл - чыгып баскан вакытлары да булган. Шуңа да Гүзәлне барсы да “ансамбль баласы” дип атап йөрткәннәр.

Самар дәүләт университетының «Социология» факультетында укыганда да талантлы кызны төрле фестивальләрдә, бәйрәмнәрдә катнашырга чакырганнар. Укуын тәмамлаганнан соң ул бер ел Самара хөкүмәтендә - өлкә губернаторы администрациясендә - эшләп ала. Ә бервакыт җылы якларда ял иткәндә булачак ире белән таныша һәм аның янына Германиягә китә.

Башка илгә килеп урнашкач, Гүзәл милләттәшләрен эзли башлый. Шулай ул 2005 елда Сабантуйда чыгыш ясап, үзенең чибәрлеге һәм искиткеч матур җырлары белән андагы татарларның күңелен яулап ала. Аның иҗатына табынучылар чибәр кызны «тылсымчы», «сокландыргыч чибәр», «Берлинның энҗе бөртеге» кебек сүзләр белән атап йөртә башлыйлар.

Берлинда Гүзәлнең «Бүләк» исемле демо-дискы да дөнья күрә. Аңа «Ялкынлы яшьлек» ансамбленең гармунчысы Наил Нурмөхәммәтовның күп кенә җырлары кертелә.

Үз вакытында Айсылу ханымның кызы “Татарлар Дойчланл” үзәге эшендә дә актив катнашып, Берлинның “Тамга” җәмгыятен оештыручыларның берсе була. 2007 елда Гүзәл Халыкара «Урмай моңы» татар җыры фестивалендә катнашып, Гран-При ала. Нәкъ икенче көнне ул инде Казанда, Халыкара «Җиде йолдыз» фестивалендә, лауреат исеменә лаек була. Уңышларына шатланып, «канатланып» Берлинга кайткан яшь җырчыны немец журналистлары һәм фотохәбәрчеләре урап алалар. Ә бер атнадан соң тышында



Гүзәл Курмаева фотосурәте төшерелгән «Контакт» журналы басылып чыга.

2010 елда Гүзәл “Берлин тавышы” дип аталган радио бәйгесендә дә җиңү яулый һәм чит илдә татар мәдәниятен пропагандалавы өчен Бөтендөнья татар конгрессының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

Бүгенге көндә дә Гүзәл Курмаева Берлин шәһәрендә яши, халыкара популяр эстрада группасында ун телдә җырлар башкара.

– *Кызым Гүзәл – минем сабыем, балам, дустым, өметем һәм таянычым. Ул илдән киткәч, мин үземне канаты сынган кош кебек хис иттем. Күңелем ничек сызланса да, кызыма, үзем яратып башкарган җырдагыдай, хәерфатихаларымны юллап торам:*

*Кошларга да канат үскәч,*
*Канатларга куәт кучкәч,*
*Калдыра бит туган оясын.*
*Әткәй-әнкәй өчен бала*
*Һәрчак сабый булып кала,*
*Язмышыбыз берук аясыз.*
*Чакыра зәңгәр офыклар,*
*Җемелдәшеп әйди утлар,*
*Көтә сезне барыр юлыгыз.*
*Борчылса да безнең күңел,*
*Янда тоту мөмкин түгел,*
*Тик бәхетле генә булыгыз, -*
*ди ямансулап Айсылу апа.*

Туган ягыннан еракта булган «Ялкынлы яшьлек» ансамбле баласы”ның барыр юллары якты, ә үзенә йолдыз булып озын-озак балкырга насыйп булсын иде.





### СЕЗНЕҢ БЕЛӘН БӘЙЛӘДЕМ МОҢЛЫ ЯЗМЫШНЫ, ЙӨРӘГЕМДӘ ҖЫР БУЛГАНГА СӨЯМ ТОРМЫШНЫ!

Ягымлы, көләч йөзле, аралашучан, күзләре йолдызлардай янып торган Айсылу Әбдиеваның яшәү девизы: *“Бернәрсәгә дә карамастан, күңел төшенкелегенә бирелмәскә, ешрак елмаерга, ә елыйсы килгән чакларда - җырларга!”* Шуңа да искиткеч тавышлы һәм оптимизм белән сугарылган җырчы халык күңелен җәлеп итмәслек түгел шул!



35 ел дәвамында ансамбльнең иң кирәкле асылташы булып торган Айсылу ханым үзен бик бәхетле дип саный. *«Зур сәхнәләргә чыгып җырлау мөмкинлеген Аллаһы Тәгаләнең миңа биргән зур бүләге итеп кабул итәм. Ансамблебезнең җитәкчесе Илгиз абый Колючевка олы рәхмәтләремне җиткерәм»,* - ди ул.

Кызганычка, бүген Айсылу Әбдиева кебек милли мәдәниятебезгә, матур традицияләребезгә ихлас күңелдән гашыйк, җан атып йөрүче кешеләр еш очрамый шул. Безнең алда шундый кыйммәтле асылташыбызны зурлау, яшь буынны алар үрнәгендә тәрбияләү бурычы торадыр, дип уйлыйм.

*- Айсылу апа, Сезгә мәдәният өлкәсендәге күпьеллык нәтиҗәле хезмәтегез өчен нинди дә булса мактаулы исем бирелсә дә, бик аз булыр сыман,* - дидем мин гомер йомгагын сүткән әңгәмәдәшемә.

*- Чыннан да, ансамблебезнең җитәкчесе Илгиз абый Колючев һәм өлкәбездә эшләп килүче татар оешмаларының җитәкчеләре иҗади юбилеем уңаеннан хезмәтемне танырга һәм бәяләргә кирәк, дип табалар һәм бу хакта уйланалар икән. Рәхмәт яусын үзләренә, -* дип серен ачып салды Самарның атаклы татар җырчысы.

Тормышның һәр мизгелендә гел матурлык тудырып яши белүче һәм тирә-юньдәгеләргә дә бары тик яхшылык теләүче, күңелле ял сәгатьләре бүләк итүче “моң чишмәсе”н иҗади 35 еллык юбилее белән тәбрикләп, мин дә аңа үз рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Киләчәктә дә Айсылу апа Әбдиевага үз кыйбласына тугры калырга, янәшәдәгеләргә үрнәк, якыннарга терәк-таяныч, оптимист булып яшәргә насыйп булсын. Аның иҗат чишмәләре язгы ташкыннардай ургысын, күңелендә һәрчак шатлык булып, ул аны гел сәхнәгә, тамашачылар алдына җилкендереп торсын иде!



# НЕ ПРОФЕССИЯ, А ПРИЗВАНИЕ

**Будучи по своему первому образованию технологом по переработке нефти Флорида Аглямовна ЛУКМАНОВА пришла в культуру совершенно случайно, можно сказать, не думая, не гадая, не ставя перед собой судьбоносный выбор. Просто однажды, уже в далеком 1987 году, на улице наткнулась она на объявление о том, что в куйбышевский кинотеатр "Вымпел" требуется методист без специального образования и заинтересовалась должностью. Через два года целеустремленную и энергичную работницу кинотеатра замечает директор Дворца культуры завода «ЦСКБ-Прогресс» (ныне Дворец культуры на площади им. С.М. Кирова) Иван Яковлевич Кононенко. Уже на следующий же день Флориду Лукманову переводят во Дворец культуры на должность администратора. И вот с тех пор минуло 25 лет... А за это время в сознании наших соплеменников ДК на площади имени С.М. Кирова превратился в центр культурного досуга татарского народа.**
**К тому же в этом году остающаяся всегда молодой и красивой Флорида Аглямовна отпраздновала и свое 60-летие. Одни юбилеи... А они обязывают подводить итоги...**

**Римма НУРЕТДИНОВА**

Родилась и выросла героиня моей публикации третьим ребенком в интеллигентной семье в Благовещенском районе Республики Башкортостан. Позже, когда девочке исполняется 14 лет, их семья переезжает в Уфу. Ее мама Ракия Гильмияновна Гильмутдинова, всю жизнь проработавшая в школе учителем, являлась яркой общественницей, окончила партийную школу, была секретарем обкома комсомола республики и директором школы. Отец Аглям Шакирович Шакиров, окончивший библиотечное отделение Уфимского культурно-просветительского училища, заведовал Домом культуры. Поэтому девочка с детства была знакома со сферой, в которой в последующем и сама нашла свое призвание. Ведь росла она, наблюдая за репетициями и мероприятиями в ДК, самая первая прикасаясь ко всем книжным новинкам библиотеки.

Флорида, еще совсем юной, на летних каникулах у родственников в деревне знакомится со своим будущим супругом. Курсант Пермского военного училища Камиль, также приехавший гостить в село к своим родным, увидев красавицу, влюбляется в нее до беспамятства и начинает добиваться взаимности у девушки. Несколько лет любовных переписок молодых заканчивается красивой свадьбой, и с тех пор Флорида Аглямовна, как жена декабриста, всюду следует за своим любимым мужем.



*Маленькая Флорида с матерью Ракией Гильмияновной Гильмутдиновой*

Сначала, по распределению супруга, молодая семья отправляется в Казахстан, потом в Германию, где пять лет проживают в военном городке под Берлином. Флорида-ханым, у которой была явная склонность к изучению языков еще в школе, довольно комфортно ощущает себя за границей. Она, благодаря базовым школьным знаниям и при помощи словаря, легко объясняется с немцами, жены военных всегда просят ее сопровождать их за территорией гарнизона.

Живут супруги и в Москве, где Камиль Калимуллович оканчивает Военную академию имени Жуковского, а в 1986 году переезжают в Куйбышев.

В 1976 году в семье рождается сын Руслан. Спустя семь лет дочь Юлия радует супругов своим появлением.

Тем временем Флорида-ханым трудится по своему первому образованию техником-технологом в нефтеперерабатывающих предприятиях и проектных институтах. Но по



*Флорида, еще совсем юной, знакомится со своим будущим супругом Камилем*

воле судьбы, как уже упоминалось выше, она устраивается методистом в куйбышевский кинотеатр, а затем и администратором во Дворец культуры...

Именно в сфере культуры Флорида Лукманова находит свое призвание, поэтому заочно получает высшее образование в Самарском государственном институте искусств и культуры. Сегодня она уже не представляет себя без своей профессии, ибо в ней не просто работает, а живёт.

В течение 25 лет работа во Дворце культуры на площади имени С.М. Кирова била ключом – это и проведение театрализованных праздников, различных мероприятий по календарным датам, смотров, фестивалей, концертов, спектаклей и вечеров. Всего и не перечислишь. Трудно переоценить вклад ДК в общественную и культурную жизнь города. Нарядный люд шел сюда на праздниках и в будни. А сколько событий помнит его концертный зал! Какие таланты блистали на его сцене! Какие самобытные артисты радовали зрителей своими яркими выступлениями!

Двери ДК всегда открыты для юных талантов и творческих коллективов. Среди них известные и любимые многими зрителями артисты: музыкально-хореографический ансамбль «Искорки», ансамбли эстрадного танца «Акварели», «Академия танца», детская цирковая студия «Фейерверк», вокальные группы «Коломбина», «Веселые нотки», «Студия гитаристов», «Хор русской песни», «Хор ветеранов войны и труда». Ни одно календарное мероприятие в ДК не обходится без выступлений этих коллективов.



*Несколько лет любовных переписок молодых заканчивается красивой свадьбой*

Дворец никогда не пустует и является тем островком культуры, где людям по-настоящему хорошо. Здесь также придают большое значение вопросам национального единства и патриотизма. Понимание и поддержку в ДК находят национально-культурные центры. Татарские, башкирские, чувашские и мордовские организации стали завсегдатаями этого Дворца, так как в нём их слышат и дают зелёный свет всем инициативам.

В течение четверти века для наших соплеменников ДК на площади имени С.М. Кирова начал ассоциироваться с центром культурного досуга татарского народа. Сначала здесь показывали индийские фильмы с татарским переводом, затем начали проходить концерты татарстанских артистов и национальные мероприятия.

Флорида Аглямовна и по сей день помнит тот день в далеком 1989 году, когда познакомилась с одним из основателей областного татарского общества «Туган тел» Азатом Камиловичем Надировым. Он в рюкзаке принес во Дворец культуры видеокассеты с индийскими фильмами на татарском языке. Привозил энтузиаст их из Казани для того, чтобы показать куйбышевским соплеменникам и тем самым пробудить у них интерес к родному языку. Тогда администратор ДК поддержала идею этих киносеансов и зачинщики нового дела собственноручно сели писать афиши с приглашением соплеменников и расклеивали их по всему городу.



*В 1976 году в семье рождается сын Руслан*



*Флорида Лукманова с сыном гуляют по Берлину*

Спустя несколько лет дочь Флориды Аглямовны, Юлия, обучавшаяся в детской музыкальной школе, участвовала на первом областном татарском фестивале детских творческих коллективов «Поют татарские дети», проводимом обществом «Туган тел». Девочка сыграла на фортепиано композицию «Ай, былбылым». Тогда талантливую Юлию запомнили многие соплеменники и с тех пор начали узнавать и ее инициативную маму - администратора ДК на площади им. С.М.Кирова Флориду Лукманову.

В начале 90-х годов Флорида Аглямовна знакомится с известным в татарских кругах бизнесменом, чемпионом Европы и СССР по дзюдо Хабилем Хазиевичем Бикташевым, к которому до этого обращались все татарстанские звезды с просьбой помочь организовать и провести концерты на куйбышевской земле. С тех пор именитый соплеменник начинает отправлять татарских певцов к Флориде Аглямовне Лукмановой. Администратор ДК до сих пор хорошо помнит, как собирала зрителей на первый татарский концерт – на программу артистов Фирзаря Муртазина и Альфии Абзаловой. Тогда ей помогли распространить билеты сотрудница татарской газеты «Бердэмлек» Марьям Низамова и продавец татарских видеокассет на различных национальных мероприятиях Амирхат Сытдиков. Флорида-ханым так же по сей день хранит афишу первого концерта на самарской земле ныне популярного певца Салавата Фахретдинова.



*Флорида-ханум и Камиль-эфенде в апреле 2015 года отпразднуют 40 лет совместной жизни*

Учитывая то, что за последние годы внешняя и внутренняя отделка ДК на площади им. С.М. Кирова сильно обветшала, да и техническое состояние оставляет желать лучшего, Флорида Аглямовна пробовала перенести татарские концерты и на другие площадки – пыталась провести их базе Окружного Дома Офицеров и культурно-развлекательного центра «Звезда», однако эта затея не сработала… Оказалось, что самарские татары предпочитают прежнее место для концертов, да и звезды эстрады за многие года привыкли к стенам старого ДК.

Сегодня Флорида-ханым общается и дружит со многими татарскими певцами, лично знакома с членами их семей, поздравляет их со всеми праздниками, даже ездит к ним в гости. Семья Лукмановых также часто бывает и у своих родственников в Уфе, где все близкие вместе собираются за одним праздничным столом.

Уже давно выросли дети Флориды-ханум и Камиля-эфенде, которые в апреле следующего года отпразднуют 40 лет совместной жизни. Сын Руслан пошел по стопам матери и окончил Самарский государственный институт искусств и культуры, однако не стал работать по профессии, а стал торговым менеджером. Дочь Юлия с красным дипломом окончила факультет иностранных языков Самарского государственного педагогического университета, работает аналитиком в крупной организации и преподает английский в детской студии.

Наверное, многие, прочитав данную публикацию, нарисовали в своих воображениях деятельность Флориды Лукмановой как красочные веселые мероприятия. И кажется, что у нее не работа, а сплошные праздники, благо в нашем календаре их большое количество. А ведь на самом же деле эта составляющая - только парадный фасад огромной



*Семья Лукмановых*



Награждение Флориды Лукмановой Благодарственным письмом Губернатора за большой вклад в сохранение и развитие татарской культуры и национальных традиций на территории Самарской области

шать. Специфика ее работы - особая, прежде всего, она заключается в непосредственном общении с людьми. За годы работы у нее выработалось особое чувство коллективизма, чувство членов артели. И поэтому ей неуютно без коллектива и друзей.

*- Работа – моя жизнь, без культуры я себя уже не представляю. Мне всегда хотелось объединить много людей для тёплого, доброго общения. Чтобы свет культуры смог зажечь каждого и помог раскрыть все те дарования, которые нам даны свыше.*

*У меня не так часто бывают выходные, а когда такие дни случаются, не умолкает мой домашний телефон. Я всегда нахожусь в курсе всех рабочих моментов. Бывает и такое, что я откладываю отдых, домашние дела и еду проведать свой родной Дворец культуры.*

работы, лишь часть того огромного объема процедур, которыми наполнен ежедневный труд. Сколько времени уходит на подготовку и организацию праздников и концертов, сколько бессонных ночей – не сосчитать!

На хрупких плечах Флориды-ханым лежит большая нагрузка и ответственность за качественное проведение во Дворце культуры всех мероприятий. Талантливая, инициативная, энергичная соплеменница является прекрасным администратором, контролирующей работу всего необходимого персонала от гардеробщиц и билетерш до профессиональных звукорежиссеров.



Награждение Флориды Лукмановой Благодарственным письмом Всемирного конгресса татар

Да, свою работу администратор ДК очень любит. Она сумела выстроить добрые отношения со всеми службами и руководителями, с кем приходилось иметь дело. Ее ответственность, неравнодушие и готовность помочь ценятся и простыми людьми, и в высоких кабинетах.

За свою плодотворную работу Флорида Лукманова имеет множество благодарственных писем от Губернатора Самарской области Н.И. Меркушкина, председателя Самарской Губернской Думы В.Ф. Сазонова, департамента по вопросам культуры, спорта, туризма и молодежной политики Самарской области, главы администрации Кировского района г.о. Самара Ю.Н. Денисова, Всемирного конгресса татар, от татарской, башкирской, чувашской и мордовской национально-культурных организаций области.

Сегодня Флорида Аглямовна, находясь на заслуженном отдыхе, продолжает заниматься своей профессиональной деятельностью в ДК, является активистом областного татарского общества «Туган тел». Для неё важно жить в культуре, ибо эта область деятельности всё равно, что воздух, без которого нельзя дышать.

*Благо муж меня всегда понимает и поддерживает. Одним словом, я счастливый человек во всем! У меня есть любимая работа, семья и, конечно, мои соплеменники!* - признается Флорида Аглямовна.

Да, она по-прежнему энергична, полна вдохновения и идей.

Давно остались позади непонимание домочадцев из-за ее постоянного отсутствия у родного очага, уже не упрекают друзья, что она не поддерживает их компанию. Все знают, ее жизнь – это работа администратором во Дворце культуры на площади им. С.М. Кирова.

# ИШАН ХӘЗРӘТ ДОГАСЫН АЛГАН ЧЕРКЕЛИ КЫЗЫ

**Әй, гүзәл татар хатын-кызы! Тормышның нинди генә өлкәсен алма, һәр җирдә да бу назлы зат катнаша. Хәтта күбрәк ир-атка хас булган эшкуарлык эшен дә уңышлы алып баралар алар.**

**Әңгәмәдәш – Миләүшә ГАЗИМОВА**



Шундыйларның берсе - Самарның “Татар кухнясы” хуҗабикәсе, күптән түгел Фәхретдин Канюкаев канаты астында оештырылган “Ак калфак” татар хатын-кызлары оешмасы җитәкчесе  Әзимҗан кызы Разия Әюпова.

Шунысы мактауга лаек. Аның бизнесы татар милли хәрәкәте белән бергә үрелеп бара. Разия апаның кафесы татар учагы булып тора. Эшкуарлык белән милли хәрәкәтне аермыйча, бизнес үзең өчен генә түгел, ә халык өчен булганда гына мәгънәле һәм уңышлы була, ди ул.

**– Разия ханым, бизнеска ничек килеп кердегез?**

– Мин бизнесымны үзгәртеп кору чорында ачтым. Ул вакытта тормыш үзе шундый таләпләр куйды дисәң дә була. Хезмәт хакы кечкенә, аны да вакытында түләмиләр.

Узган гасырның 92нче елларында кызым Наилә белән Төркиягә йөреп, сатуга киемнәр алып кайта башладык. Ул елларда бик күпләр Төркиядән, Эмираттан, Мәскәүдән сатуга тауар ташырга тотындылар. Сатучылар күбәйде, базар ачылды.

– Бу сүз минем, кызларым Наиләнең һәм Галиянең исемнәренең иҗекләреннән төзелде.

Кызым Наилә белән без Төркиягә, Грециягә бик күп йөрдек. Төркиядән – тире, Грециядән туннар алып кайттык.

Бизнеска күчкәнче, Төркиядә булган бер хәл турында сөйләп китәсем килә, чөнки бүген бу актуаль мәсьәлә булып тора. Хәзер бит инде төрле төбәкләрдә президент урынына регион башлыгы дияргә кирәклеге турында сүз бара. Татарстанда исә моңа каршы киләләр. Һәм бу дөрес тә. Чөнки миңа президент исеме бервакыт бик булышты.

Кызым Наилә белән Төркиянең кибетендә туннар, курткалар алдык та, бу тауарга бөтен акчабыз киткәнен аңладык. Ә бит әле өйгә кайтып җитәргә дә, күчтәнәчләр, бүләкләр алырга да кирәк. Инде нишләргә, дип баш ватам, үземнән генә догаларымны укып, Аллаһыдан ярдәм сорыйм. Хәзер кибетнең хуҗасына “Россия, Ельцин”, дип әйтеп карадым. Янәсе, мин Россиядән, миңа бераз ташлама ясагыз. Ә ул борынын җыерды да,  инглизчә “No, no”, дип кулын селтәде. Әхә, мәйтәм ошамады. Аннан соң “Татарстан, президент Минтимер Шәймиев, welkom”, дим. Шуннан хуҗа сатучысын алып китеп, үзара нәрсә турындадыр серләштеләр дә, безгә кофе ясап китерделәр һәм тауарыбызга яхшы ташлама ясадылар.

Мин инде үземчә Аллаһы Тәгаләгә дә, аларга да, президент Минтимер Шәймиевка да рәхмәтләремне укыдым шунда. Менә бит безнең кебек гади кешеләргә дә, әле Россиядә яшәүчеләргә, президент сүзенең файдасы тиде.



Аннан Осипенко урамында аерым салон ачып җибәрдек. Ә тора-бара бу бизнесым тулысынча кызым Наиләгә калды. Мин исә 95 – 96нчы елларда, Гагарин урамына күчкәч (рәхмәт яугыры Вазыйх Гатович Мөхәммәтшин миңа ул вакытта бик булышты), шунда ук ризыклар кибете ачтым.

Хәләл итләр дә саттык. Энем Идрис авыллардан терлек сатып алып кайтып, аларны үзе суя иде. Аннары итне сатуга әзерли. Ул миңа

Безгә дә әйберләрне сатар өчен урын кирәк бит инде хәзер. Наилә кызымның ире, офицер киявем Әнвәр: “Әни, бу эшне закон кысаларына кертеп, рәсми теркәргә һәм кибет ачарга кирәк. Мин булышам”, - дип тәкъдим итте. Шулай итеп, Ленинградский урамында урнашкан “Детский мир” кибетенең бер бүлеген арендага алдык. Аның җитәкчесе, милләттәшебез Зөләйха ханымга рәхмәт инде. Үтенечебезгә каршы килмәде. Бүлегебезне “Розалина” дип атадык.

**– Ә ни өчен нәкъ “Розалина”?**


Разия ханым кызлары Наилә һәм Галия белән

бик зур ярдәм күрсәтте, Аллаһының рәхмәте яусын үзенә. Ит, балык белән бәйле авыр эшләрне ул бик яратып башкарды. Аннан сатучы итеп Лидия Михайловна исемле бер бик оста пешекчене эшкә алдым. Ул кибетебездә пәрәмәчләр, өчпочмаклар пешереп, салатлар ясап сату мөмкинлеге турында сүз кузгатты. Ике бүлмәле кибетнең берсенә өстәл, урындыклар куеп, аны кафе сыманрак ясап куйдык. Үзебездә пешкән өчпочмакларны, пәрәмәчләрне, токмачны, бәлешне кешеләр бик яратып ашадылар.

Ул вакытта "Ак бәхет" радиосы гөрләп эшләде бит. Анда алып баручылар әтиле-кызлы Шамил абый Баһаутдин белән Наилә Сабирҗанова безнең кафеда татар ризыкларын авыз итәргә була дип, сөйләп тордылар. Аннан Шамил әфәнде миңа "Татар кухнясы" ачарга тәкъдим ясады. Шулай тора-бара меню төзеп, кечкенә кафебыз тулы канлы "Татар кухня"сына әйләнде, кибет исә элеккегечә эшләде.

"Ак бәхет"тән сандугачыбыз Наилә Сабирҗанова игълан иткәннән соң, халык безгә бик күп килә иде.

Шулай ук "Бердәмлек" гәҗитәсе, анда эшләгән журналист Раушания Ситдыкова безнең эшебез турында һәрвакыт язып тордылар.

Мин Шамил абый белән Наиләгә мең рәхмәтләремне әйтәм, чөнки нәкъ алар миңа "Татар кухнясы"н ачарга этәргеч бирделәр һәм пропагандаладылар.

Безнең кафега бик күп татарлар йөри башлады. Балалар фестивален оештырган Шамил Баһаутдин белән Азат Надиров районнардан килгән



Разия Әюпова «Татар кухнясы»нда «Чәкчәк» бәйрәменә әзерләнә



*Разия ханым туганнары арасында*

балаларны безнең кухняга алып килделәр. Аларны бушлай сыйладык.

“Яктылык” мәктәбе төзелгәндә аның мөдире Хәридә ханым Дашкина да төзелеш буенча кешеләр белән очрашуларын еш кына бездә үткәрә иде.

Шамил абый Баһаутдин Казаннан килгән танылган җырчылар - Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, “Сөембикә” журналы хезмәткәрләре, Илсаф, Нәфкать Нигъмәтуллин, Салават, Хәмдүнә Тимергалиева, Гөлдания Хәйруллина, Илшат Вәлиев, Рөстәм Асаевны да “Татар кухнясы”на чакырды. Ә Хәбил Бикташев бездә Галиәсгар Камал театры артистларын сыйлый иде.

Фәхретдин Канюкаев, Али Сөләйманов, Рифкат Хуҗин һәм башка татар егетләребез еш кына бездә кунак булдылар. Алар бөтенесе дә минем балаларым кебек.

Шулай әкрен генә безнең кухня татар учагына әйләнде, һәм мин татар милли хәрәкәтенә кереп киттем. Бүгенге көндә “Ак калфак” татар хатын-кызлары оешмасы әгъзалары да һәрвакыт диярлек бирәдә җыелып, чаралар, җыелышлар үткәрәбез.

Аллаһыга шөкер, мине бу эшемдә бик күп татарлар хуплап торды-



*8 Мартка президент Минтимер Шәймиев котлаганда. Разия Әюпова (сулдан уңга), Раушания Ситдыкова, Наилә Сабирҗанова, Хәридә Дашкина*

лар, тормышымда һәрвакыт яхшы кешеләр очрады. Азат абый Надиров кафены бизәр өчен үзе ясаган картиналарны бүләк итте. Шамил абый еш кына килеп, эшләребезнең ничек баруы белән кызыксына иде. Ул кафебызга татар төсмере кертү, биредә татар мохиты булдыру өстендә туктаусыз эшләп торды. Безнең халык бик яхшы, мәрхәмәтле. Ярдәмгә килделәр, рәхмәт яугыры.

“Татар кухнясы”нда эшләгән кызлар – Әлфия, Венера, Фәния, Алисәне әле дә рәхмәтләр белән искә алам. Кызым Галия җитәкчелек итә, ә Наилә кызым исәп-хисап мәшәкатьләрен алып бара.

Татарлар гына түгел, урыс халкы да йөрде. Тирә-якта эшләүчеләр төшке ашка киләләр иде. Сездәге кебек тәмле чәй беркайда да юк, дип мактыйлар. Ләкшәне (безнең Ульян ягында токмачны ләкшә диләр) бушлай бирдек. Бәяләр бездә арзан иде.

Безгә йөргән халыкның иң яраткан ризыкларының берсе – чәкчәк тарихын да сөйләп үтим әле. Ирем Шамил белән якын дусларыбыз Абделкадыйр белән Әминә Әмировларга кунакка баргач, анда бик тә тәмле чәкчәк авыз иттек. Әминә ападан аны кайдан алганнары турында кызыксынмыйча кала алмадым. Ул миңа Самарда Нурания исемле хатынның чәкчәк пешереп сатуын әйтте һәм миңа аның телефон номерын бирде. Мин Нурания ханымга шалтыратып, рецептын сорадым. Рәхмәт, каршы килмәде. Әле аннан соң да чәкчәк пешерә башлагач, еш кына аңарга шалтыратып, киңәшләр сорый идем. Шулай чәкчәкне үзебездә ясый башладык.

Шуны әйтәсем килә. Ул елларда татар кафесы халыкка бик тансык иде. Әйтерсең лә алар моны көтеп алганнар кебек булды.

Бүгенге көндә кафедагы эшләрнең күбесе Галия кызыма төшә. Ул ашлар да пешерә, чәкчәкләр дә ясый, оештыру эшләрен дә башкара. Әле дә ярый аның балалары ярдәм итә. Оныкларым Динар, Сания бу эшне бик яратып, тырышып эшлиләр. Гомумән, алар татар дөньясын, татарча киенергә, яулык бәйләп йөрергә яраталар. Мин моңа шатланып туя алмыйм.

**– Хатын-кызга, эшкуар булыр өчен, нинди сыйфатлар кирәк?**

– Иң беренче кешеләрне яратырга кирәк. Ягъни үзең өчен генә акча эшләү түгел, ә халык өчен тырышу булырга тиеш, чөнки башка очракта бизнесның мәгънәсе югала.

Шулай ук әхлаклы булу, үз эшеңне ярату мөһим.

Бизнесың уңышлы барсын өчен табышыңнан өлеш чыгарырга кирәк. Шулай мин мәчетләргә, ятимнәргә, мескеннәргә ярдәм күрсәткәлим.

**– Көндәшләр белән мөнәсәбәтләр ничегрәк иде?**

– Татар кафелары ачарга ашкынып торучылар булмады. Мин тыныч кына эшлим, конкуренция турында уйлаганым да юк. Шулай бервакыт берәү килеп, сезнең көндәшегез барлыкка килде - "Царь Солтан" рестораны ачылган, диде. Ә мин үз халкыбызның шушындый затлы ресторан ачуына шатландым гына. Әгәр дә татарлар шулай кафелар, ресторannар ача икән, бу көндәшлек түгел, ә, киресенчә, сөенеч, чөнки милләтебез үсә, чәчәк ата, дигән сүз. Хәтта мин аларга ярдәм күрсәтергә дә әзер. Миңа конкуренция сүзе бер дә туры килми. Мин булышып яшәү ягында.

**– Сезнең туган авылыгыз – Черкелидән чыккан күпләр – бизнес кешеләре, хәлле халык. Моның сере нидә?**

– Бу сорауга җавапны Черкелидә яшәүче дустым Әминәнең улы Әхмәт Рамазанов турында сөйләп башлыйсым килә. Аларга кунакка баргач, аның юлларны яңартканына, елга аша кечкенә күпер салганына шаккаттым. "Дустым, мул тормыш алып барасың, шөкер", - дидем аңа. Ул исә: "Әйе, Аллаһыга рәхмәт яусын, авылдашларым белән бу эшләрне дә башкардык, зиратларны да чистартып торабыз. Кирәксенгән кешеләргә "Камаз"ымны да биреп торам.

Табышымнан халыкка өлеш чыгарам. Шуңа Аллаһы Тәгалә үземә дә бирә", - дип җавап бирде.

Шулай итеп, дустым мисалында Черкели авылы халкының Аллаһы рәхмәте өчен эшләүләрен күрсәтәсем килде. Алар кечкенәдән шундый тәрбия алганнар.

Шулай ук безнең авылга Ишан хәзрәтнең изге догасы төшкән, дип сөйлиләр. Ишан хәзрәт хәлле кеше була. Мәрхәмәтле, ярдәмчел имам мәчет-мәдрәсәләр төзеткән. Моның өчен ул Ульян өлкәсенең төрле авылларыннан хезмәткәрләрне эшкә алган. Аннан соң хезмәтләре өчен кем нәрсә тели - йә акча, йә бодай, йә агач белән түләгән. Безнең Черкели кешеләренә чират җиткәч, ул: "Рәхмәт. Ни телисез – шуны бирәм", - ди. Черкелиләр исә: "Юк, Ишан бабай, безгә бернәрсә дә кирәкми. Син безгә үз догаңны гына бир", - диләр. (Бу турыда Ишан хәзрәтнең оныгы Иршат хәзрәт Сафинның "Меңнәрнең остазы" дигән китабында җентекләп язылган). Шулай итеп, авылыбызга аның догасы төшкән, шуңа күрә эшләребез дә уңышлы, кешеләр дә хәлле, диләр.

**– Татар кешесенә күтәрелергә авыр, аның йә башына сугалар, йә чабуыннан тоталар, йә ачыктан-ачык милләте белән хурлыйлар. Сезгә бизнес ачканда шундый авырлыклар очрадымы?**

– Әйе, мондый хәл булды шул. Хөкүмәттә миңа кафены "Татар кухнясы" дип атарга рөхсәт итмәделәр. "Теләсә нинди исем бирегез, тик "татар" сүзе булмасын", - диделәр. Мин кайгыга төшеп, яңадан Шамил абый Баһаутдин янына бардым. Аңарга бу сүзләрне җиткергәч, Шамил әфәнде миңа: "Башка бер җиргә дә йөрмә, "Татар кухнясы" дип яз да куй", - диде. Шулай "Татар кухнясы" дип атадым. Әле ике ел эшләгәннән соң да, безгә килеп, кафеның исемен үзгәртергә куштылар. Тик без сөйләшеп, бу мәсьәләне җайладык.

**– Эшкуарлык белән шөгыльләнә башлар өчен ни кирәк?**

– Иң беренче, әлбәттә, акча, тик аны иплә кенә тотарга кирәк. Чын эшсөяр акчаның кадерен белә. Закон таләпләрен үтәү мөһим.

Алда әйткәнемчә, кешеләрне яратырга, ачык йөзле, тәмле телле булырга кирәк. Шушы сыйфатларга ия эшбатырның эше барачак.

Сөйләшүебезне тәмамлап, шуны әйтәсем килә. Хәлле спонсор тарафыннан кухнябызга яхшы гына ярдәм булса, аны заманчарак, затлырак итеп үзгәртергә, яңартырга, тагын да матурлатырга мөмкин булыр иде. "Татар кухнясы"ның дәрәҗәсе зур. Аның тышкы кыяфәте дә югары дәрәҗәгә туры килсен иде. Бу мәсьәләне дә, бәлки, хәл итеп булыр, Аллаһы теләсә.



*Разия ханымның иң олы абыйсы Кәшшаф янында*

# ЛЮДИ ИДУТ ПО СВЕТУ



Выверен старый компас,
получены карты и сроки,
Выштопан на штормовке
лавины предательский след.
Счастлив, кому знакомо
щемящее чувство дороги.
Ветер рвет горизонты и
раздувает рассвет.

**Не надо говорить, будто в наш рациональный век начисто перевелись романтики. Не надо думать, что экстремалы – это сплошь суровые мужчины с накачанными мышцами, а для женщин привычнее место у кухонной плиты и у детской кроватки. Надо знать, что современная женщина удивительно сочетает в себе прелесть тургеневских нежных созданий и силу и стойкость «джек-лондонских» героинь. К таким умозаключениям я пришла после встречи с Альбиной Газизулиной, которая вместе с двумя подругами прошлым летом совершила автомобильное путешествие на Байкал. Большинство окружающих, как и следовало ожидать, восприняли ее замысел как сумасбродство и чистейшую авантюру. Забегая вперед, скажем, что таких скептиков после их возвращения в окружении путешественниц поубавилось. Но обо всем – по порядку. Послушаем, что говорит сама Альбина о той поездке.**

**Собеседница – Миляуша ГАЗИМОВА**

**– Альбина, расскажи сначала немного о себе.**

– Родилась я в Узбекистане, в городе Ангрен. 15 лет своей жизни прожила там, пока родители не приняли решение переехать в Татарстан.

В 2005 году после окончания Уруссинской татарской гимназии я поступила в Самарский государственный аэрокосмический университет. В 2011 году я успешно окончила первый факультет аэрокосмического университета по специальности "Самолето- и вертолетостроение" и осталась здесь работать. В 2013 году поступила в аспирантуру на кафедру производства летательных аппаратов и управления качеством в машиностроении (специальность - стандартизация и управление качеством продукции). Сейчас активно занимаюсь над диссертацией.

**– У тебя есть хобби?**

– Я стараюсь успеть многое: встречаться с друзьями, связать модную штучку, прочитать книгу, рисовать, посмотреть новый фильм или сходить в театр, путешествовать. Любое увлечение всегда интересно и позволяет человеку жить насыщенной, полноценной жизнью.

**– Какой девиз жизни?**

– Невозможно победить того, кто не сдается и с хорошим настроением идет вперед, не оглядываясь назад!

**– Ты с подругами совершила путешествие на Байкал. Довольно рискованное мероприятие для молодых девушек. Как зародилась такая идея, и как прошло путешествие?**

– Мысль побывать на Байкале никогда меня не покидала, еще в школьные годы я точно для себя определила, что обязательно там побываю. Оставалось только придумать, когда, как и с кем это сделать? Организованный туризм со случайно набранным контингентом не для меня. Лететь самолетом – дорого, по железной дороге – долго. Путешествие нелегкое и недешевое. Поняла, что лучше поехать на своем автомобиле, что дает свободу выбора маршрута и, если хотите, даже некое чувство собственной крыши над головой.



О предстоящем отпуске я всегда начинаю задумываться уже весной. В университете отпуска у преподавательского состава почти всегда приходятся на летние месяцы. Оставалось прозондировать, кто и как относится к путешествию на автомобиле и смогли бы они поехать со мной на Байкал. Среди мужчин ни у одного не встретила понимания: от первой же фразы «на Байкал на автомобиле» они шарахались в сторону. А вот среди подруг моя идея имела успех. Антонина Кочян (доцент кафедры космического машиностроения, 30 лет), а потом мы уже вдвоем «обработали» Екатерину Громову (доцент кафедры ПЛА и УКМ СГАУ, 31 год).

Создали «В контакте» общий диалог, где обсуждали все нюансы и разжигали свою страсть к поездке.

Решили ехать на машине Антонины, по сравнению с другими она была больше и имела открытую страховку. Двигаться к Иркутску и обратно решили не спеша, продвигаясь в день по 900-1000 км с ночлегом. Планировали заезжать в крупные города, чтобы посмотреть их достопримечательности.

Порывшись в интернете, определились с познавательным маршрутом: Иркутск-Листвянка-Ольхон-Кругобайкальская железная дорога-Иркутск. Нам казалось, что основные достопримечательности и хорошая дорога находятся именно на этом участке.

Вот так в феврале родилась идея о путешествии на автомобиле к самому глубокому озеру планеты.

Конечно, мы понимали, что поездка не из легких и следовало проверить друг друга, прежде чем отправляться в такое путешествие. Больше всего нас волновала совместимость интересов и поведение на дороге, манера вождения, ориентация в незнакомых городах и на трассе. Поэтому перед путешествием на Байкал мы решили совершить пробную поездку в незнакомый для всех нас город. Выбрали Екатеринбург. Поехали туда на майские праздники. Чуть было не сорвали подготовку к параду, посвященному Дню Победы, припарковавшись на главной площади города, зато мило пообщались с ГАИ города Екатеринбурга, благо телефон оставили под стеклом, искать машину на штрафстоянках не пришлось.

Поездку на Байкал запланировали на август. Маршрут был просчитан, запланированы пункты остановок и составлена приблизительная программа посещения достопримечательностей на маршруте.

И мы отправились навстречу приключениям!

Выехали в 5 утра 4 августа 2014 года. Первой за руль села Антонина, а потом мы меняли друг друга через каждые 300-350 км.

Днем проехали Башкирию. Удивительнейшая природа. Дорога проходит среди холмов, покрытых бархатом зелени, в палитре которой переливались теплые желтоватые оттенки. Всю эту красоту покрывала легкая голубоватая дымка, сгущаю-



щаяся на горизонте. Сквозь облака, то там, то здесь проглядывали солнечные лучи.

С каждым часом заметно менялся ландшафт. Мощные глыбы и перепады Уральских гор сменялись равнинами с обилием озер и болот, которых становились меньше с каждым километром. В районе Кургана по обе стороны дороги перед нами раскинулись уже поля и степи, украшенные пучками смешанных лесов.

Первую ночь мы провели в г. Кургане, после чего решили, что останавливаться надо в крупных городах. Выбора особого не было, надо было отдохнуть хорошенько и на утро двигаться дальше. Маршрут запланирован был через Казахстан. Проходить границу оказалось несложно и достаточно быстро. Поездка по Казахстану оказалась скучноватой, дорога скучная, степи, шел дождь.

Омская область встретила нас радугой, посчитали, что это очень хороший знак. Решили остановиться в Омске на обратном пути, а по пути туда переночевали в придорожном отеле "Еврозона".

Далее по маршруту у нас был запланирован Новосибирск. Расстояние от Омской области до Новосибирска не очень большое, поэтому в Новосибирске мы были засветло, сняли квартиру на сутки, посмотрели достопримечательности и наутро отправились в путь, к цели!

Погода была прекрасная. Дорога красивая. Эти удивительные и разные пейзажи только подтверждали, что путешествие на автомобиле – был наш правильный выбор. Наутро из Новосибирска мы отправились в Красноярск! Расстояние немалое, но решили остановиться именно в этом городе. Очень хотелось посмотреть достопримечательности Красноярского края. Заповедник «Красноярские столбы», Красноярская ГЭС оставили о себе незабываемые впечатления, что словами не передать, и мы решили непременно вернуться в это удивительнейшее место еще раз на обратном пути.




Следующим пунктом был Иркутск. Мы были совсем близки к цели. Счастье переполняло нас!

**– Что запомнилось больше всего?**

– Первым мы посетили поселок Листвянка, расположенный на берегу Байкала в 65 километрах от Иркутска. Там имеются знаменитый Байкальский лимнологический музей и нерпинарий. А со смотровой площадки "Камень Черского" открываются удивительные пейзажи. От красоты и масштабов этого памятника природы захватывает дух. Больше всего запомнилась байкальская вода. Она уникальна и удивительна, как и сам Байкал. Необыкновенно прозрачна, чиста. Недаром, в не столь уж и давние времена она считалась целебной, с ее помощью лечили разные болезни. Местные жители до сих пор рассказывают о ее удивительных свойствах.

Далее по бездорожью мы отправились к сердцу Байкала – на остров Ольхон. Весь остров пропитан древними легендами и историческими преданиями (мыс Саган-Хушун, скалы "Три брата", мыс Хобой, гора Жима, мыс Шунтэ-Левый, скала Шаманка – одна из святынь Азии, мыс Бурхан со сквозной пещерой в Шаман-скале и т.д.). У каждого из этих мест своя легенда, своя история. Надо сказать, что о. Ольхон крупнейший и единственный обитаемый остров озера Байкал. С северо-западным берегом озера образует проливы Малое море и Ольхонские ворота. Попасть на остров можно с помощью паромной переправы "Ольхонские ворота" (для туристов) и "Дорожник" (для местных жителей).

В очереди на паромную переправу мы стояли шесть часов, и нам еще повезло, что это было во вторник, а не в выходные дни. По острову мы доехали до п. Хужир, распложенный вблизи мыса Бурхан. Хужир – самый крупный населенный пункт на острове. Сняли на острове домик,





договорились об экскурсиях по острову и наконец-то поняли, что завтра нам не надо рано вставать, не надо никуда торопиться, и можно искупаться в озере-море!

Вода у о. Ольхон прогревается до 18-20 градусов, температура воздуха 25-28. Ветер. На Ольхоне встречается всё многообразие ландшафтов природы: степь, песчаные пляжи с дюнами, холмами и рощами вдоль берега, а также мраморные скалы и болота. На острове мы попробовали национальные блюда бурят, байкальского омуля, съездили на лежбище тюленей. Какие это милые, обаятельные и поразительно добрые существа!

Нам так не хотелось уезжать из Ольхона. Каждый день мы встречали рассветы и провожали закаты. И каждый из них был неповторим по красоте.

На 13-й день своего путешествия мы решили проехаться по кругобайкальской железной дороге. Ну не могли мы быть так близко и не уделить внимания несокрушимому памятнику XIX века! С одной стороны – скалистые утесы, с другой, почти вплотную, воды Байкала. Образец гармоничного взаимодействия человека и природы: мост, каменная арка, тоннель – кажется, вечно были здесь, а не построены руками человека. Будучи самой короткой по протяженности, тем не менее, она оказалась самой сложной по особенностям строительства в основном из-за характера местности и сложных геологических условий. Путешествие по КБЖД продлилось около 12 часов. Кстати, КБЖД была нашим крайним пунктом в путешествии по Байкалу. В планах было съездить и в Улан-Уде, но так как нам очень понравился отдых на Ольхоне и уезжать очень уж не хотелось, мы решили оставить Улан-Удэ на следующий раз, а лишних пару дней провести в прекрасном городе Красноярске и в заповеднике Красноярские столбы.

**– Затраты были большие?**

– На путешествие на троих потратили около 90 000 рублей с учетом бензина, ТО, проживания и питания. Накрутили на спидометре 9696 км.

**– Не страшно было так далеко выехать девушкам?**

– О страхе никто из нас даже и не задумывался, был азарт, интерес. И потом, я всегда не понимала, когда мне говорили: “В такие поездки надо ехать минимум на двух машинах?”. Чем поможет мне вторая машина?

**– То есть ты любишь путешествовать?**

Путешествовать очень люблю. Идея поездки на автомобиле возникла давно. Хотелось бы и в Европу на автомобиле съездить, но с нынешними санкциями сложно что-то планировать. Есть идея посетить еще одно озеро на нашей планете.

**– Где еще бывали, или Байкал - это первое такое путешествие?**

– Путешествие на Байкал – первое подобного рода путешествие. Стойкое убеждение того, что первая поездка должна быть по территории родной страны – не покидало меня никогда.

**– Собираетесь ли еще на такое авантюрное путешествие? (улыбка)**

– Собираемся. Есть идея посетить еще одно озеро - Иссы́к-Ку́ль. А еще очень хотелось бы посмотреть на Байкал зимой, у него удивительный лед, говорят местные жители. Но это уже другая история.





# БАЛАЧАКТАН БЕР КӨНЕМ

**Балачактан хатирәләр уелганнар күңелемә гомерлеккә
Барлый-барлый, түкми-чәчми тезәм мин аларны җепкә...**

**Наилә ХӨСӘЕНОВА**

Бу хатирәмне Санюк исемле сыердан башлыйм, һәм бу юкка түгел. Санюк кызыл төстәге бик матур, сөтле терлек булса да, аның кирелеге безгә дә, күршеләргә дә, авыл көтүчеләренә дә яхшы билгеле иде.

65 – 70 елларда авылда атлары булмаган кешеләрнең күбесе, сыерларын җигеп, печәнен, утынын ташыдылар. Йорттан тирес чыгару, бәрәңге алып кайту кебек эшләр дә сыер ярдәме белән башкарылды.

Иртән көтүгә куылган Санюкны кичен өйгә алып кайту миңа йөкләнгән булгач, мин аның артыннан инештәге күпернең бу ягына барып, көтеп тора идем.

Шушы җиргә җиткәч, көтүче сыерларны инеш янында туктатып, су эчерә. Ә аннан алар инде үзләре йортларына кайтып җитәләр.

Тик безнең кире сыерыбыз еш кына өйгә кайтмый иде. Инештән су эчкәч, ул китә дә югала. Аны эзләп, күпме күз яшьләрем түгелүе әле дә истән чыкмый.

Әгәр дә Санюкны каршы алырга биш кенә минутка булса да соңга калсаң, бетте, аны тиз генә табам, дип уйлама да. Ул шунда ук, упкынга баткан кебек, юкка чыга иде.

Ә минем, 7 – 8 яшьлек баланың, башына нинди генә уйлар килми! Бүре ашамаса ярый иде, упкынга батып үлмәсен иде, кирәгеннән артык ашап, күбенмәсә иде, колхоз ашлыгына кереп, аны каравылчылар тотмасын иде, дип, догаларымны укый-укый эзлим үзен.

Санюкны таба алмыйча, өйгә кайтып, әби белән энидән шелтә сүзләре ишеткән чаклар да күп булды. Ул бит безнең ашатучыбыз иде. Гаиләне сөт, каймак, катык, эремчек белән тәэмин итә. Әле үзебездән калганнарын базарга чыгып сата да идек. Менә шул сыйфатлары өстенә тагын бер мөһим әйбер әйтеп үтәсем килә. Ул һәр ел безгә бер матур гына бозау бүләк итә иде. Шундый иде безнең Санюгыбыз! Әлбәттә, без дә аны, халык кебек үк җигеп, ат урынына да куллана идек. Җигәр алдыннан ул җигү әйберләрен, арбаны күргәч үк үзенең холкын күрсәтә башлый. Арба тәртәсе артына басмый, хамытларын кимичә, муенын тирә-якка боргалый, капкадан чыкканда аның баганасын ватып чыгардай була. Шулай итеп, безгә буйсынырга теләмәвен белгертергә тырыша ахрысы. Тик ни дә эшләп булмый, шундый ысул белән кышка җитәрлек, без аңарга да, сарыкларга да печән, өй ягырлык утын хәстәрлибез.

Менә шуңа күрә әби белән энинең иртәгә урманга барганнарын ишеткәч үк, минем дә, сыерныкы кебек, күңелем төшә иде. Гомердә дә мин аларга бармыйм, дип әйтмим, тик, бәлки, әле иртә белән яңгыр явар, урманга барырга туры килмәс, дип, үз-үземне генә тынычландыра идем. Шул вакытларда “Ник соң этием юк, этиле кешеләрнең балалары әби-эниләре белән печән, утын хәстәрләп йөрмиләр”, - дип, зар кыла идем.

Иртән таң алдыннан кызарып чыккан кояш нурларын күргәч, өметемнең юкка чыкканы аңлашылды. Хәтимә әбиемнең йомшак итеп чәчемнән сыйпап: “Тор, балам, күгәрченемнең күк түшкәсе, кызыл тәпие син, энкәң сыерны җикте, юлга чыгарга вакыт”, - дип, мине назлы итеп күтәреп торгыза да, яңа сауган сөтне кулыма тоттырып, эчәргә булыша иде. Минем йоклыйсым килгәнне белеп, әйдә, балакаем, арбага хуш исле печән салдым, юлда йоклап барырсың, дип, юатып куя иде. Ул вакытта мин әле күп нәрсәне аңламый идем. Хәзер озак вакыт үткән инде.

Бүген дә әбиемнең елмаю аралаш чыккан күз яшьләрен күңелемдә саклыйм. Нинди наз, ярату, җәлләү хисләре иде аның карашында. Ни дә эшләп булмый шул, минем кебек баланы өйдә ялгызын калдырып китәргә курку, ә икенче яктан булышуым бик аз булса да, минем урманда үз вазыйфаларым бар иде. Шулай итеп, хуш исле печән өстенә ятып, әбиемнең догаларын, көйләгән моңнарын тыңлап ята идем. Мин, әлбәттә, юлда йокламый идем. Шагыр-шогыр иткән арбага утырып, чакырлы-чокырлы юлда барганда, йокы дигәннәре бер мизгелдә юкка чыга. Анда утырып баруы да бик кыен, эчеңдә булган бөтен нәрсәләреңне астын өскә китерә иде. Әле сыерның да бер туктап, бер чабып, өркеп китүе дә теңкәңә тия. Бик тә инде тауга менәргә һәм таудан төшәргә яратмый иде Санюк.

Ул вакытларда, әнием арбадан төшеп, сыерның башыннан тотып: “Курыкма, мин янәшәңдә”, - дигәндәй, алар икәүләшеп бергә атлыйлар иде.

Шундый “Сират күпере” кебек авыр булган юлны үтеп, урманга җитә идек. Әнием чалгы, әбием урак белән урган печәнне җыеп арба янына ташучы мин идем, әлбәттә.

Шул арада сыерга да күз төшергәләп алырга кирәк була иде, чөнки ул үзен бәйләгән дилбегәсенә чоргалырга мөмкин.

Әле бит, хайваннарны чыгырыннан чыгаручы кигәвеннәр, чебенчеркиләр дә урманда бик күп. Алар Санюкны тешләп, бөтен яктан чолгап алалар. Эш арасында шуларны куарга да өлгерергә кирәк. Тик өстә язылган хәлләрне авыр, дип әйтсәм дә, күңел күтәренкелеге безне ташламады.

Печән чабып, әзрәк арыгач, ял итәргә утыра идек. Үзебез белән алып килгән ипи, сөт, үләнле чәй, йомырка Аллаһының оҗмах ашлары кебек тоела иде. Әбием белән әнием ял иткәндә мин чәчәк бәйләмнәре җыеп, ялгыз гына хыялланып, йә көйләп, йә шигырь рифмалаштырып, урман буйлап йөрергә яраттым.

Әзрәк ял итеп алгач, печәнебезне арбага төягәч, кайтасы юлга чыга идек. Киңәнечебезне яшереп булмый, печәнне күп итеп җыялдык, Ходайга шөкер. Хайванга авыр булмасын, дип, үзебез арбага утырмыйча, аның янәшәсендә атлый идек. Әнием инде сыер янында барса, без әбием белән арба артыннан кайтабыз. Әбием, урагын җилкәсенә сала да, минем кулымнан ала. Ниләр генә сөйләми иде ул шундый вакытларда. Үзенең яшьлеген, ачлык елларны ничек ялланып, Иделнең аръягында эшләүләрен, сугыш елларын, авыл халкының ничек төшкенлектә гомер итүен.

Рамазан бабама ничек кияүгә урлаганнарын. Аның хатыны үлеп, дүрт бала белән калган була. Үзләренең ике балалары тугач, ничек куанганнарын. Авылларда медицина ярдәме булмагач, ” тиф”, “оспа”, тагын әллә нинди эпидемияләрдән авыл халкының бик күпләп үлеп бетүләрен. Һәм шул елларда бабам да үлеп китә. Әбием шул алты бала белән ялгыз калып көн күрүен бәйнәбәйнә сөйләве бүгенге кебек исемдә. Кайчак күңеле нечкәреп, сөйләвеннән туктап, халык җырларын яки бәетләр көен моңлы итеп суза иде. Сабыр холыклы әбиемнең күңелле хәлләр сөйләп, туйганчы көлдергән чаклары да күп булды.

Үзем дә уйланып, кара әле, ул вакытта нинди тормыш авыр булган, ә халык барысына да түзеп яшәгән, хәзерге авырлыклар белән чагыштырсаң, алар каршында бер ни дә юк кебек тоела. Сугыш юк, ашарга, эчәргә, өскә кияргә - бөтенесе бар.

Менә кышка җитәрлек печәнен, утынын ташыдык, шөкер Ходайга, дип, нәни күңелем белән шатланып куйдым.

Өйгә җиткәч, әнием белән икәү печәнне кибәргә җәерәткәнче, әбиемнең самавыры кайнаган, бәрәңгесе пешкән була инде. Мин тиз генә базга төшеп, катык белән каймак менгерәм, һәм яңа җыйган мәтрүшкә белән чәй эчәргә утырабыз. Чәйләр эчеп алгач, эш бетте, дип, уйларга ярамый иде. Ике чиләкне көянтәгә элеп, урам очындагы “Воин бабай” коесына суга чаба идем. Өй эшләренә булырлык, терлекләрне эчерерлек, бакчада үскән яшелчәләргә сибәрлек су ташырга да өлгерергә кирәк була.

Дөрес, су ташырга күп вакытта әнием дә булыша иде. Аның да бит йорт эчендә эше күп, ир-ат өйдә булмагач, бөтен эш аның җилкәсендә булды. Мин аны бик жәлли идем. Тик, авырлыкларга карамыйча, күңелем күтәренке, дөньям төгәл иде. Биткашны юып, тупны яки сикергечне алып, әшнә-дуслар янына урамга чаба идем. Нишлисең, ул вакытта мин нибары 7-10 яшендәге бала гына идем шул...



Искиткеч матур табигатьле Иске Мастяк авылы (Ульян өлкәсе) кочагында назланып үскән, хәзер Самар шәһәрендә гомер итүче Наилә ханым Хөсәенова – нечкә күңелле, романтик хыяллар дөньясында яшәүче кеше. Аның күңел байлыгы, йөрәк хисләре шигырьләрендә чагылып җанланалар.

Аның хикәяләрендә, шигырьләрендә хатын-кызлар язмышы күп урын ала.

Табигать, ана теле, туган ил, мәхәббәт, дин турында булсынмы, Наилә ханымның һәр шигыре әйтерсең лә ниндидер тылсымлылык белән сугарылган. Аларны бер укысаң, һаман укыйсы килеп тора.

Аеруча мәхәббәт темасына шигырьләр, хикәяләр язарга ярата ул.

- Хәзерге катлаулы тормышта кайчак мәхәббәт кенә кешене дөньяның ыгы-зыгысыннан коткарып кала, - ди Наилә ханым.

Тик биредә сүз ир белән хатын арасындагы мәхәббәт турында гына түгел, ә туган илгә, якын кешеләренә, дингә, дусларыңа карата булган мәхәббәт турында да бара.

Наилә Хөсәеннованың челтерәп аккан чишмәдәй моңлы күңеленнән көннән-көн матур сихри юллар үрелә бара. Наилә ханымга иҗатында зур уңышлар, саекмас илһам насыйп булсын иде.

## Ак әбиләр

Ак яулыклы, олы җанлы
Авылым әбиләре.
Диспе тарта, намаз укый
Догада гел үзләре.

Ак яулыктай пакь күңелләренә
Яман хисләр хас түгел.
Иман юлыннан атлыйлар
Тайпылмыйча бер мизгел.

Тугры булып гомерлеккә
Калган туган-дустына.
Мәхәббәтнең иң тугрысы
Булган туган ягына.

Уңган куллар урак урган,
Җиңел тормыш күрмәгән.
Оекбаш, бияләй бәйләп,
Бишек җырын көйләгән.



Үскән бала, туган онык,
Булган хөрмәттә ире.
Сабыр сөйкемле холкы,
Бәхеткә тулган күге.

Текер-текер ак әбиләр
Атлый авылым юлыннан.
Шундый изге әбиләрдән
Урамнарга нур тулган.

Шушы назлы кочакларда
Үсә татар нәселе.
Чибәр кызлар, батыр уллар -
Милләтнең киләчәге.

## Бетәр, диләр

Кемгә сөйлим икән серләремне,
Кемнәр аңлар мине, кем тыңлар?



Кочак тулы сагыш кочып калдым,
Синсез ата хәзер ал таңнар.

Көн агышын айга тиңләп яшим,
Синсез вакыт туктап калгандай.
Иртә дә юк, көн дә, бер тоташ төн,
Сине миннән урлап алгандай.

Сулышымны чикләп, йозак салган
Ян алалмыйм күкрәк тутырып.
Күз яшьләрем буа бугазымны,
Елый алмыйм үкереп, кычкырып.

Бетәр, диләр, вакыт үтәр, диләр,
Йә үрсетеп шулай сөйлиләр.
Ялгыз калдым, синсез яшәү юктыр,
Дөньям үлде, шуны белмиләр.

## Гашыйк булдым сиңа...

Әллә инде гашыйк булдым сиңа,
Сине генә йөрим гел уйлап.



Урамнарны урыйм эзләреңне эзләп,
Болыннарга төшәм су буйлап.

Гашыйк булдым сиңа, әйе, гашыйк,
Сиздеңме икән син дә шушыны?
Керфегеңне бер күтәреп карадың да,
Һәм аңладың кебек уемны.

Көмеш сипкән чәчләремне сыйпап,
Соңгы мәхәббәтме сүз алды?
Синең күзеңдә дә алтын көзнең төсе,
Учак булып кинәт кабынды.

Йөрәгемнән чыккан хисләремә хәзер
Баш булалмый тора акылым.
Төнге күктән янып, якты йолдыз
булып,
Кочагыңа синең атылдым.

Очып китәр кошлар көен тыңлап,
Без биибез соңгы вальсны.
Рәхмәт язмышыма, биреп татлы
хисләр,
Көзен кайтарганга бу язны.

## Әллә инде кайтырга?

Әллә инде кулым селтәп шәһәренә,
Туган якка кайтып китәргә.
Буразнада, кырда, болынында
Калган гомерләрне үтәргә.

Әй, ялыктым тәмле суын эчеп,
Авылымны кысып кочарга.

Гыжлап торган иген өсләреннән
Башакларын сыйпап узарга.

Кулларымны җәеп, күкрәгемне
тутырып,
Саф һавасын аның суларга.
Кичләрендә, инеш буйларында
Кәккүкләрнең тавышын тыңларга.

Ник кайтмаска? Мин бит авылымның
Җир-куенында үскән баласы.
Шәһәр ваннасына "төкереп", әллә
инде
Мунчаларга кереп каласы.

Туфлинең дә үкчәлесен салып,
Яланаяк җирдә йөрисе.
Әллә кемнәр язган җырны
җырламыйча,
Халык көен моңлы көйлисе.

Кайтыйм берүк, кирәгем бардыр,
бәлки,
Сагынып каршы ала дус-әшнәм.
Эзләремне саклап калган юллар,
Күзне йомып аннан үтәләм.

Чит җирләрдә генә туган авылын
сагынып,
Яза димәсеннәр кешеләр.
Кизләү кебек чыккан иҗатымны
Туган җирдә туган дисеннәр.

## Үземә дә ачмыйм серемне

Гомер үтеп бара, күпме сүзләр
Сөйләнелгән аның юлында.
Бер генә сүз әйтә алмый калдым,
Очрашканда синең янында.

Каушамыйм да, холкым андый түгел,
Югалып та калып интекмим.



Синең генә янәшәңдә хикмәт,
Таштан койган һәйкәл сыман мин.

Әйтә алмыйм аны, сиңа гына түгел,
Үземә дә ачмыйм серемне.
Тик йөрәгем генә буйсынмыйча
моңа,
Гел кабатлый синең исемеңне.



Үкенү хисе җанны телә хәзер,
Әйтмәгән сүз тетте дөньямны.
Бер генә сүз, тик мәгънәсе аның
Әйләндерде бөтен җиһанны.

## Әниемнең дусты

Хәтеремдә: әнкәй сыерын сатты,
Күңеле ярсып, чыкты яшьләре.
Әллә шунда аңладымы икән
Дәрт-дәрманы ташлап киткәнне.

Текәлде дә күзе бер ноктага,
Озак кына дога укыды.
Гомеремнең бер кисәге идең, дип,
Шатландымы әллә юксынды.

Ризыгы да калды хайванымның,
диде,
Нишләтермен соң аны мин әле.
Кулына алып, битенә назлап куйды,
Үзенең кулы чапкан печәнне.

Сөтен, маен күрше-күләнгә дә
Кучтәнәчкә биреп яшәде.
Баласы да, дусты булды кайчак,
Эч серен дә аңа сөйләде.

Сабыр бул, дип, юатырга теләп,
Әнием иңен сыйпап кагылдым.
Аклап хәлен, ниләр сөйләсәм дә,
Кирәкле сүз таба алмадым.



Калдыр, кызым, диде, үтәр инде,
Бәхил булып киткән булсачы.
Йортым ятим калды, җансыз,
Шуны күрү миңа бик ачы.

## Без бит татар!

Без бит татар, аны яшерүдән
Бер Аллаһым Үзе сакласын!
Бөек динебез тиңсез, үлмәс телебез
Янәшәдә мәңге атласын.

Милләт хисе саекмаса иде,
Һәр татарның сеңеп канына.
Түбәсенә сугып, тез чүктермә, булыш
Янәшәңдә барган дустыңа.

Көнчелекне куеп аргы якка,
Кул сузыек туган һәм дуска.
Бер-береңне эттәй күреп яшәү
Дан арттырмый безнең тарихка.

Күкрәк сугып, сөйләп маташмыек,
Бөек сүзләр, матур әйтемнәр.
Эшең белән исбат итүеңне
Үз тирәңдә кешеләр күрсеннәр.

Бер кыйблага карап, дога кылсак,
Миһербанлык чәчеп як-якка.
Кабер ташы гына булып эзебез дә
Югалып калмас килер мираска.

Бер-беребезгә татулык, хөрмәт
белән
Яна белсә безнең йөрәкләр.
Шунда гына башка милләт халкы
Бу татар! дип, безне хөрмәтләр.

# ГЫЙЛЕМЛЕ ОСТАБИКӘ ҺӘМ ЯГЫМЛЫ ХАҖИЯ

**Ислам диненең тыю һәм тыелу дине булуы дөресме? Ислам динендә хатын-кызларның нинди хокуклары бар? Менә шушы һәм башка күп төрле сорауларга остазыбыз Вагыйз кызы Сания ханым Мингачева белән әңгәмә кордык. Матур, бай төсләргә күмелгән алтын көз иртәсендә Сания ханым белән очрашырга барганда мин аның бүген юбилей бәйрәме икәнлеген белә идем. Бу сөйләшүебез сезгә комачауламасмы, дип, пошынуым юкка гына булып чыкты. Елмаеп, ул бу очрашуның бәйрәмгә ямь генә өстәгәнен белдерде.**

*Наилә ХӨСӘЕНОВА*



**– Сез дини гаиләдә тәрбияләгәндегез, үз гомерегезне дә дингә багышладыгыз. Бу юлны сайлауда нәрсә этәргеч булды?**

– Миңа бу юлны сайлауда гаиләбездәге дини традицияләр сәбәпче булды. Әти-әниебез безгә кечкенәдән дин тәртибен өйрәтеп үстерде. Без энеләрем белән балачактан үзебезне мөселман дип тоеп яшәдек. Элек, динсезлек чорында да, без ураза да тоттык, намаз да укыдык. Моны кешеләргә күрсәтергә тырышмадык. Тик күңелебездә Аллаһы Тәгаләгә ышану һәрвакыт яшәде.

**– Сания ханым, сез күп илләрдә булдыгыз, дөньяны күп күрдегез. Мөселман хатын-кызына дөньяви дәүләттә яшәве авырмы? Мәсәлән, кием һәм эш ягыннан. Аңа биш тапкыр намаз укырга да кирәк бит әле.**

– Киемгә килгәндә, Коръәндә хатын-кызга битен, кулларын, аякларын ашык сөягенә (щиколотка) кадәр генә күрсәтергә ярый, дип язылган. Ә киемнең төсе, фасоны хатын-кыз үзе теләгәнчә була ала. Тик үтәкүренмәле һәм тәнгә сыланып торган гына булмасын. Ә менә башка яулык бәйләү, һичшиксез, мәҗбүри. Аның күркәм сыйфатлары бар. Яулыкны матур итеп, төрлечә бәйләргә була. Ул хатын-кызны бизи.

Ә инде эшкә килгәндә, анда намазга да, Рамазан аенда уразага да урын булырга тиеш. Үзегезгә уңайлы графиклы эшкә өстенлек бирергә кирәк. Әгәр инде нининдидер киртәләр барлыкка килеп, намазны вакытында укый алмыйсың икән, аны өйгә кайткач та кайтарып укып була. Башка диннәргә караганда, Исламда бу тыелмаган.

**– Ә хатын-кызга мәчеткә барырга, фотосурәткә төшәргә, фотоларны интернетка чыгарырга буламы?**

– Хатын-кызга мәчеткә йөрергә ярый. Әни-әбиләребез дә йөргәннәр. Анда бит ирләр белән хатыннар аерым намаз укыйлар.

Мөселманнарга фотосурәткә төшәргә дә ярый. Тик фотоларны кеше күрерлек итеп өйдә элеп куярга, шулай ук аларны интернетка чыгарырга ярамый. Фотосурәтләрне фотоальбомда сакларга кирәк, чөнки рәсем эленгән өйне фәрештәләр урап узалар, диелә хәдистә.

**– Бизәнүгә, чәч буяуга Ислам динендә караш нинди?**

– Өйдә ирең өчен бизәнү дә, чәч буяу да тыелмый. Кыска итәкле күлмәкне дә кияргә була. Тик бу ирең өчен генә, аның теләкләреннән чыгып эшләнергә тиеш.

Өйдә пычрак киемнән, тузган баш белән йөреп, өйдән бизәнеп-ясанып чыгып китү урамдагы ирләр өчен генә булмыймы соң? Ә инде хатын-кыз өйдә бизәнеп-ясанып йөри икән, урамга чыкканда да шулай матур итеп киенеп, бизәнеп чыгу тыелмый, ире рөхсәт итсә. Ире башка хатын-кызларга күз салмасын өчен өйдә бигрәк тә матур булырга тырышырга кирәк.

Буялган тырнаклар белән намаз уку катгый тыела, намазыңны Аллаһы Тәгалә кабул итми.

**– Хәзер бик күп хатын-кызлар пластика операцияләр кулланалар. Бу турыда Исламда ни әйтелә?**

– Медицина күрсәткечләре буенча кеше саулыгына зарарлы булган кимчелекләрне (мәсәлән, борын бөлгесенең кыегайганы сулыш алуга комачаулаганда) пластик хирургия ярдәмендә төзәтергә ярый. Ләкин иреннәрне калынайту, күкрәкләрне зурайту катгый тыела. Аллаһы Тәгалә биргән матурлыктан ямь табып яшәргә кирәк. Боларны үтәмәгән кеше мөселманлыгын югалта.

**– Мөселман илендә яшәүче хатын-кыз Россия хатын-кызыннан нәрсәләре белән аерылып тора?**

– Анда хатын-кызлар үзләренең хокукларын яхшы белеп яшиләр. Шуңа күрә алар, безнең кебек, башларын бөгеп, ике кулына да авыр сумкалар тотып, чабышып йөрмиләр. Әкрен генә итеп, башларын күтәреп, патшабикәләрдәй йөзеп йөриләр. Алар үзләренең ышанычлы яклаучылары барын яхшы беләләр.

Бу төрле яктан сизелә. Мәсәлән, егет кәләшне сорарга баргач, кызга мәһер (бүләк) бирергә тиеш. Кәләшнең теләге буенча бу машина да, өй дә булырга мөмкин. Әгәр инде ире белән аерылышырга туры килсә (гәрчә ул илләрдә бу сирәк очрый) дә, ирнең бу кыйммәтле бүләге хатынга кала. Шуңа күрә анда өйләнергә бик авыр, чөнки гаилә корыр өчен акча җыярга күп вакыт кирәк. Һәм шуның өчен аерылырга да бик ашыкмыйлар.

**– Согуд Гарәбстанында берничә хатынга өйләнү гадәте гади хәл булып тора, диләр?**

– Бу анда гына түгел, хәзер бездә дә инде күп таралды. Татарстанда ике-өч хатын белән торучылар бар.

Дини китапларда бу турыда шулай язылган. Әгәр дә хатыннарының һәрберсен тигез күреп, аларны матди яктан, аерым яшәү урыны белән тәэмин итә алсалар, ул чара тыелмаган. Ләкин икенче, өченче хатынга өйләнер алдыннан иренә беренче хатыны рөхсәт бирергә тиеш, әмма бер хатын белән яшәү хәерлерәк.

Ислам динендә хатын-кызларга эшләмәскә рөхсәт ителә. Әгәр дә инде үзләре теләп эшләсәләр, алган маллары, акчаларын үзләренә генә тотарга мөмкин. Ә гаиләне ир-ат матди яктан тәэмин итәргә тиеш.

**– Дөрес аңласам, хатын эшләгән акча аныкы гына, ә ирләр тапкан мал уртак була?**

– Әйе, ирләр эшләп алган акчаларын хатынына, балаларына тотарга тиеш. Ә хатын-кызларның бурычлары – ирен карау һәм балаларны тәрбияләү. Бездәге кебек, анда балаларны урам да, балалар бакчасы да, мәктәп тә тәрбияләми.

**– Тик Ислам динендә хатын-кызларның изелгән булуы, хокуклары тыелганы, аларның башларын күтәреп, бер сүз әйтергә дә кыймаганлыгы күңелгә сеңеп калган.**

– Юк, Ислам дине белән хатын-кыз өскә күтәрелде. Безнең ирләр белән бертигез хокукларыбыз бар. Тик ирләрнең гаилә башлыгы булу хокуклары калды. Бу дөрес тә. Ул баш булып, гаиләсен ашатырга тиеш, чөнки ир гаиләсе алдында җавап тота. Ә Аллаһы Тәгалә каршында ирләр дә, хатын-кызлар да бертигез.

Шундый мәгънәле сөйләшүнең озакка сузылганы тоелмады да. Самарның Җәмигъ мәчетендә алган әңгәмәмнең ахырында Сания ханымны котларга килүчеләр саны арта барды. Бу көнне биредә Вагыйз кызы Сания Мингачеваның юбилеена багышланган дини мәҗлес үтәчәк.

Сания ханымны Самар татарлары арасында белмәгән кеше юктыр шикелле.

Ул көнне аны котларга мәсҗид бинасына килгән туганнарын, дусларын, шәкертләрен санап бетергесез иде.

Һәммәсенең зур шатлык белән тулган ачык йөзләре, зур-зур чәчәк бәйләмнәреннән башка, аларның Сания ханымны олылау, соклану сүзләре дә төрле яктан ишетелеп торды.

Башкача булырга мөмкин дә түгел бит. Сания ханым – күренекле, танылган дин әһеле, күп еллар өлкә мөфтие булып торган Вагыйз хәзрәт Яруллинның кызы. Ә аның энесе – Самар өлкәсенең мөфтие Талип хәзрәт Яруллин. Ире Габделәхәт хәзрәт Мингачев – Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы. Әнисе Асия абыстай Яруллинада мөселман хатын-кызына хас булган уңай сыйфатлар тупланган. Ачык йөзле, тәмле телле Асия абыстай акыллы киңәшләре белән кешеләргә ярдәм кулы сузып тора.

Кызганыч ки, үз әти-әниләрен карамаучылар да күп. Ә Яруллиннар


*Сания Мингачева һәм Наиля Хөсәенова әңгәмә вакытында*

һәм Мингачевлар үзләренә чит-ят булган кешеләргә дә булышып яшиләр. Шулай бер карчыкны үз гаиләләренә алып, аны күп еллар, ул үлгәнче тәрбияләгәннәр.

Менә шундый гаиләдә туып-үскән Сания ханым башкача яши алмый да инде.

Ул мәктәпне, медицина училищесын тәмамлап, ун ел кан салу станциясендә эшләп, үзенең гомерен кешеләргә ярдәм итүгә багышлый.

Сания ханым Габделәхәт Мингачев белән никахлашып, алар матур гына гаилә коралар.  Озакламый Бохара шәһәренә дини белем алырга китәләр. Аннан кайтып, Самар өлкәсенең Гали авылында мәдрәсә ачуга бөтен көчләрен куялар. Габделәхәт әфәнде анда имам булып хезмәт итә, ә Сания ханым балаларга һәм хатын-кызларга дини белем бирә.

Биредә берничә ел эшләгәч, 1996 – 2003 елларда Мингачевлар Согуд Гарәбстанында дини белемнәрен камилләштереп кайталар. Сания ханымның остазлык сыйфатларын ишетеп белгән кешеләр аның кайтуын зарыгып көтеп торалар.

Сания Мингачева Самар Җәмигъ мәчетендә, бөтен көчен куеп, балаларга, хатын-кызларга дини курслар оештырып, аларга гарәп графикасын, Коръән уку тәртипләрен, динебезнең тарихын өйрәтергә керешә. Аның йөрәге, күңеле аша үткән йөзләгән шәкертләре  Ислам динен тирәнтен өйрәнеп, намазга басып, аннан соң үз гаиләләренә дә дини юлда тәрбия биреп яшиләр.

Күптән түгел Сания ханым Мингачева хаҗ кылып кайтты. Аның бу гамәле дә юбилеен ямьләндерде.

Бәйрәмгә килгән шәкертләре белән аралашып, аларга остазлары турында сораулар бирдем.

Гөлсылу Вахрамова:

“Мин һәр иртә торгач, Сания ханымда дини белем алуым өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләр укыйм. Ул тормышта зур хезмәт башкара. Тыныч, сабыр остаз безгә гарәп графикасын, Коръән серләрен өйрәтә, намазга басарга ярдәм итә. Сания ханымда укый башлагач, минем тормышым яхшы якка үзгәрде. Хәзер мин мөселманнар арасында Ислам динебез өйрәткән хезмәттәшлек, ярдәмчеллек, аңлашучанлык мохитында яшим. Барысы өчен дә мин Сания ханымга бик рәхмәтле. Аңа исәнлек-саулык, ике дөньяның да рәхәтен телим”.

**Әлфия Ибраһимова:**

“Сания ханым кебек мәрхәмәтле, ярдәмчел, әдәпле, ипле ханымнар күбрәк булса иде. Ул миңа намазга басарга булышты. Шушындый остазым булганга мин бик бәхетле. Аңа сәламәтлек, озын гомер, бәхет телим. Без, аның барлык шәкертләре, Сания ханымны чын күңелдән яратабыз”.

Сания ханым Мингачеваның менә шундый күркәм бәйрәме булып үтте. Сания ханым, без сезгә киләчәктә дә изге хезмәтегездә зур уңышлар, үзегезгә һәм гаиләгезгә исәнлек-саулык телибез. Мөселман кардәшләребезгә дини белем биреп, аларны шатландырып яшәргә язсын!


LOVE
106.6 FM
SUPER MIX*
КАЖДЫЙ ДЕНЬ
НА 106.6 FM
0+
*СУПЕР МИКС


НИКА
ЮВЕЛИРНЫЕ ЧАСЫ И АКСЕССУАРЫ
Тайна в твоих руках
НИКА
Розовое золото 585 пробы.
Вставка — бриллианты.
Новинка сезона осень-зима — 2014.
www.nikawatches.ru

# ПЕЛЬМЕНИ ПО-ТАТАРСКИ С ОРЕШКАМИ



Орехи тщательно растолочь, затем слегка обжарить и перемешать с готовым картофельным пюре.

Яйцо отварить вкрутую, очистить, мелко нарезать и перемешать с пюре с орешками – если начинка получилась слишком густой, добавьте в нее горячее молоко.

Раскатать пельменное тесто, разрезать его на кусочки, на каждый выложить фарш, сформовать пельмени.

Готовить пельмени по-татарски с орешками таким образом: опустить в подсоленную кипящую воду, дождаться всплытия и достать при помощи шумовки, подавать с топленым маслом или сметаной.

**ИНГРЕДИЕНТЫ:**

- 200 г теста
- 100 г очищенных орешков
- 100 г картофельного пюре
- 1 яйцо

# ПИРОГ С КАПУСТОЙ

**Время приготовления – 2 часа, калорийность – 208 ккал.**



**ИНГРЕДИЕНТЫ:**

- Белокочанная капуста 1/4 шт.
- Мука пшеничная 200 г
- Творог 200 г
- Маргарин 150 г
- 3 яйца
- Сметана 3 столовые ложки
- Соль 0,5 чайные ложки

1. Охлажденный маргарин натрите на терке, добавьте протертый творог и муку. Посолите по вкусу и замесите тесто.

2. Готовое тесто скатайте в шар, оберните пищевой пленкой и отправьте в холодильник на час.

3. Тем временем мелко нашинкуйте капусту и обжарьте ее на растительном масле в течение 5 минут (не забывайте постоянно перемешивать). Затем добавьте сметану и жарьте еще 5 минут.

4. Добавьте предварительно отваренные и мелко нарезанные яйца.

5. Большую часть теста слегка раскатайте и выложите в смазанную маслом форму, сформировав высокие бортики. Выложите начинку и украсьте сверху полосками из оставшегося теста.

6. Отправьте в разогретую до 180 градусов духовку и запекайте до готовности примерно 35-40 минут.

# БЫСТРЫЙ ПИРОГ С ЯГОДАМИ

**Время приготовления – 45 мин.**



1. Разогрейте духовку до 200 градусов. Взбейте масло с сахаром, добавьте яйцо и кефир. Просыпьте муку, смешанную с разрыхлителем и ванилином.

2. В смазанную маслом форму вылейте тесто. Сверху выложите ягоды и посыпьте сахаром. Выпекайте 25 мин.

**ИНГРЕДИЕНТЫ:**

- Ягоды свежие 400 г
- Сахар 200 г
- Мука пшеничная 200 г
- Маргарин 150 г
- Кефир 100 г
- 1 яйцо
- Ванилин 1 чайная ложка
- Разрыхлитель 1 чайная ложка

# ЭЧПОЧМАК

**Калорийность эчпочмака составляет 396 ккал.**



**ИНГРЕДИЕНТЫ:**

- Мука пшеничная 400 г
- Творог 200 г
- Сливочное масло 200 г
- Сахар 100 г
- Сода 1/2 чайные ложки

1. Подогрейте масло, чтобы оно стало мягким.

2. Смешайте масло с творогом.

3. Влейте в смесь соду, погашенную уксусом.

4. Добавьте муку.

5. Порежьте тесто на небольшие лепешки.

6. Обваляйте лепешку в сахаре, сложите пополам, потом еще раз посыпьте сахаром.

7. Сложите из лепешки треугольник.

8. Выпекайте в духовке при стандартной температуре до готовности.

Ювелирный Дом “BritanArt” счастлив одарить финалисток Фестиваля единственными в своём роде ювелирными украшениями ручной работы - растениями облачёнными в золото.

Творчество ювелирного дома BritanArt несет внутри себя частичку живой природы навечно запечатленной в драгоценный метал.

Каждое изделие уникально и является как воплощением живой природы, так и произведением искусства.

Благодаря самой природе, вдохновению дизайнеров, рукам мастеров, и ремеслу, которое передавалось от отца к сыну, их долгому, кропотливому труду красота живых цветов сохраняется навечно.

Все изделия Ювелирного Дома “BritanArt” уникальны в своём роде: как нет двух идентичных душ, так нет двух одинаковых лепестков.

Живая и вечная красота.

**С любовью,**
**Ювелирный Дом “BritanArt”.**

*Уникальные технологии. Ручная работа!*



BritanArt
*Растения в Золоте*

Ул. Охотный ряд,2
Торговая галерея “Модный Сезон”
2 этаж, мостик, корнер BritanArt
С 10-00 До 22-00

Телефон: 8 (929) 518-17-57

http://britanart.ru

# СЛОВАРЬ ЗИМНИХ СЛОВ



Ель – чыршы
Новогодняя елка – Яңа ел чыршы-сы
Еловый лес – чыршы урманы
Варежки – бияләй
Валенки – киез итек
Гололед – бозлавык
Шуба – тун
Шаль – шәл
Пуховый платок – мамык шәл
Сани – чана
Санки – бәләкәй чана
Коньки – тимераяк
Конькобежец – тимераякта йөгерүче
Лыжи – чаңгы
Лыжник – чаңгычы
Мороз – салкын, суык
Морозный день – суык көн
Морозная погода – салкын һава
Горнолыжник – тау чаңгычысы





Лед – боз
Льдина – боз кисәге
Покрыться  льдом – боз белән кап-ланырга
Ледник – бозлык
Ледокол – бозваткыч
Ледоход – боз китү, боз агу
Дед Мороз – Кыш бабай
Снегурочка – Кар кызы
Новый год – Яңа ел
Снег – кар
Снегопад – кар яву
Снежный – карлы
Зима – кыш
Обилҗная зима –  карлы кыш
Зимний – кышкы
Мокрый снег – юеш кар
Белый снег – ак кар
Пурга – буран, кар бураны
Снеговик – Кар бабай
Снежинка – кар бөртеге
Лавина – кар ишелмәсе








В кабельных сетях Самары и Тольятти
РТВ
САМАРА
РБК
ДЕЛОВОЕ ИНФОРМАЦИОННОЕ ПРОСТРАНСТВО
СТАНЬ ЕГО ЧАСТЬЮ
16+
Приглашаем к диалогу в эфире РБК/РТВ-Самара
(846) 97-97-500

Открытое Акционерное Общество

Автовокзалы и Автостанции Самарской области




# АВТОВОКЗАЛЫ И АВТОСТАНЦИИ САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ ЭТО:

- междугородние и международные маршруты;
- современные, надежные и комфортабельные автобусы;
- возможность предварительной продажи билетов и бронирование по телефону;
- возможность покупки билетов через интернет;
- предоставление автобусов на заказ.

## ВАША ПОЕЗДКА – НАША ЗАБОТА!

**Справки по телефону: 224-25-54; 224-25-55**

**Сайт: www.avokzal63.ru**

# Яңа 2015 ел белән!

***Газиз милләттәшләр!***

*Сезне якынлашып килүче Яңа 2015 ел белән чын күңелдән тәбриклибез!*

*Тылсымлы Яңа ел төнендә һәркайсыбыз хыял диңгезендә йөзә, барлык теләкләрнең дә үтәләсенә ышана. 2015 ел сезнең өчен ышаныч-өметләрнең аклану, уй-хыялларның чынга ашу чоры булсын! Күтәренке кәеф һәм күңел көрлеге һәрвакыт изге эшләргә өндәп торсын! Сезгә һәм якыннарыгызга бәхет, исәнлек-саулык, иминлек һәм мул тормыш телибез!*

*Киләсе елларда да бергә булыйк, бердәм булыйк, милләтебезгә бергәләп хезмәт итик. Хәрәкәттә - бәрәкәт. Безне алда зур эшләр көтә!*

**Изге теләкләр белән Самар өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте президенты Ильяс Гомәр улы ШӘКҮРОВ.**

***Дорогие соплеменники!***

*Сердечно поздравляем вас с наступающим Новым 2015 годом!*

*В волшебную новогоднюю ночь в каждом из нас просыпается маленький ребёнок, мы все загадываем самые сокровенные желания и надеемся на их скорейшее исполнение. Желаем осуществления всех заветных желаний, здоровья и подъема творческих сил! Пусть счастье, удача и благополучие всегда сопровождают вас и наступающий год станет годом больших достижений и добрых дел, годом финансового благополучия и стабильности!*

*Пусть и в дальнейшем всем нам будет суждено держаться воедино, вместе служить своему народу! В движении – жизнь и сила. Впереди нас ждут большие дела!*

**С искренними пожеланиями президент Самарского областного татарского общества «Туган тел» Ильяс Гумерович ШАКУРОВ.**

*Хөрмәтле милләтәшләр!*

*Барыгызны да якынлашып килүче Яңа 2015 ел белән котлап, исәнлек-саулык телибез. Гаилә бәхетегез тулы булсын, күңелләрегездә тынычлык хөкем итсен. Киләчәк көнгә ышаныч белән яшәгез. Күтәренке кәеф һәм күңел көрлеге һәрвакыт изге эшләргә өндәп торсын!*

*Киләчәктә дә бердәм булыйк! Халкыбыз берләшкән очракта гына, туган телебезне, милли мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калачакбыз.*

*Бәйрәм белән!*

**Самар өлкә татар эшкуарларына ярдәм итү ассоциациясе.**

***Дорогие соплеменники!***

*Поздравляем всех вас с наступающим Новым 2015 годом. Желаем вам отменного здоровья, семейного счастья, душевного спокойствия, неизменного оптимизма, неиссякаемой веры в себя. Пусть приподнятое настроение, чистота помыслов и души помогают вам творить благородные дела.*

*И в дальнейшем мы должны оставаться единым народом! Только так нам удастся сохранить родной язык, национальную культуру, свои традиции и обычаи.*

*С праздником!*

**Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области.**

Туган тел

АССОЦИАЦИЯ СОДЕЙСТВИЯ ТАТАРСКИМ ПРЕДПРИНИМАТЕЛЯМ САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ

# С Новым 2015 годом!

САМАРСКОЕ ОБЛАСТНОЕ ТАТАРСКОЕ ОБЩЕСТВО
«Туган тел»

# Туган тел

ОСНОВАНО В 1989 ГОДУ

# Нам 25 лет!

www.samtatnews.ru
tugantelsamara@bk.ru